ИНСПЕКЦИЯ ГОСУДАРСТВЕННОГО СТРОИТЕЛЬНОГО НАДЗОРА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ДӘҮЛӘТ ТӨЗЕЛЕШЕН КҮЗӘТҮ ИНСПЕКЦИЯСЕ

ПРИКАЗ | БОЕРЫК
26.07.2016 | Казан | № 48

**Татарстан Республикасы Дәүләт төзелешен күзәтү инспекциясенең 04.12.2013 № 94 боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Дәүләт төзелешен күзәтү инспекциясе тарафыннан Татарстан Республикасында төбәк дәүләт төзелеш күзәтчелеге буенча дәүләт вазифасын башкаруның административ регламентына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы Дәүләт төзелешен күзәтү инспекциясенең ведомство буенча норматив актларын 2008 елның 26 декабрендәге “Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшмәкәрләрнең хокукларын яклау турында” № 294-ФЗ Федераль законга, Россия Федерациясенең Шәһәр төзелеше кодексына, Экологик, технологик һәм атом күзәтчелеге буенча федераль хезмәтнең 2006 елның 26 декабрендәге № 1129 боерыгы белән расланган Дәүләт төзелешен күзәтүне тормышка ашырганда тикшерүләр үткәрү цәм төзелгән, үзгәртеп корылган, төзекләндерелгән капиталь төзелеш объектларының техник регламентларның (нормаларның һәм кагыйдәләрнең), башка норматив актларның, проект документларының таләпләренә ярашуы турындагы бәяләмәләрне бирү тәртибенә (РД-11-04-2006) кертелгән үзгәрешләргә туры китерү максатларында боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Дәүләт төзелешен күзәтү инспекциясенең 04.12.2013 № 94 боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Дәүләт төзелешен күзәтү инспекциясе тарафыннан Татарстан Республикасында төбәк дәүләт төзелеш күзәтчелеге буенча дәүләт вазифасын башкаруның административ регламентына (алга таба – Регламент), аны яңа кушымта булып килүче төзәтмәсендә раслап, үзгәрешләр кертергә.

2. Татарстан Республикасы Дәүләт төзелешен күзәтү инспекциясе (алга таба – Инспекция) башлыгының дәүләт төзелеш күзәтчелеген турыдан-туры гамәлгә ашыручы урынбасарларына, Инспекциядәге структур бүлекчәләрнең җитәкчеләренә, Инспекциядәге вазифаи затларга:

2.1. гамәли эшчәнлекләрендә шушы боерык белән расланган Регламент нигезләмәләренә тайпылышсыз таянып эш итәргә;

2.2. шушы боерык белән расланган Регламентны Инспекциядәге белгечләр тарафыннан өйрәнүне оештырырга һәм шушы боерык белән расланган

Регламентта каралган тиешле документацияне тулы күләмдә кертүне (шул исәптән мәгълүмати материаллар формалаштыруны) тәэмин итәргә.

3. Инспекциядәге хокукый идарә башлыгына (Раимов Ш.Н.) әлеге боерыкны Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында дәүләт теркәвенә алу өчен тапшырырга һәм аны рәсми бастырып чыгару өчен җибәрергә.

4. Инспекциядәге җыелма анализ бүлеге башлыгына (Вишнякова С.Г.) шушы боерык белән расланган Регламентны Татарстан Республикасы Хөкүмәтенең Рәсми порталында Инспекция субпорталында һәм "Дәүләт органнарының һәм җирле үзидарә органнарының эшчәнлеге турындагы мәгълүматтан файдаланунын тәэмин итү турында"гы Федераль закон нигезләмәләре нигезендә Татарстан Республикасының дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр порталында урнаштырырга.

5. Әлеге боерык, Регламентның 2017 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә торган 1.9 п. 11, 12 пунктчаларыннан кала, аны бастырып чыгарган көннән башлап үз көченә керә.

6. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча үземне җаваплы итеп билгелим.

Башлык вазифаларын башкаручы И.Ф. Сафиуллин

Татарстан Республикасы Дәүләт
төзелешен күзәтү инспекциясенең
2016 елның 26 июлендәге
№ 48 боерыгы белән расланды

**Татарстан Республикасы Дәүләт төзелешен күзәтү инспекциясе тарафыннан Татарстан Республикасында төбәк дәүләт төзелеш күзәтчелеге буенча дәүләт вазифасын башкаруның административ регламенты**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

Дәүләт вазифасының аталышы

1.1. Әлеге Административ регламент (алга таба – Регламент) "Татарстан Республикасында төбәк дәүләт төзелеш күзәтчелеген башкару" (алга таба – дәүләт төзелеш күзәтчелеге) дәүләт вазифасын (алга таба – дәүләт вазифасы) тормышка ашырганда Татарстан Республикасы Дәүләт төзелешен күзәтү инспекциясенең (алга таба – Инспекция) административ процедураларының тәртибен, вакытларын һәм эзлеклелеген билгели.

Дәүләт вазифасын башкаручы Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органының аталышы

1.2. Дәүләт вазифасы Татарстан Республикасының Дәүләт төзелешен күзәтү инспекциясе тарафыннан үтәлә.

Дәүләт төзелешен күзәтү инспекциясенең структур бүлекчәләре булган территориаль органнары (алга таба – территориаль органнар) дәүләт вазифасын турыдан-туры үтәүчеләр булып санала.

Дәүләт төзелеш күзәтчелеге турыдан-туры Инспекция башлыгының (башлык урынбасарының) тиешле боерыгы (әмернамәсе) нигезендә Инспекциядәге дәүләт төзелешен күзәтүгә вәкаләт бирелгән вазифаи затлар (алга таба – вазифаи затлар) тарафыннан тормышка ашырыла.

Дәүләт төзелеш күзәтчелеге Инспекция тарафыннан прокуратура, үзеннән-үзе җайга салынулы оешмалар, эксперт оешмалары, дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, юридик затлар һәм шәхси эшмәкәрләр, гражданнар белән аларның мөрәҗәгатьләре буенча үзара хезмәттәшлек итү нигезендә башкарыла.

Инспекциянең территориаль органнары тарафыннан тикшерүләр үткәрү, лаборатор һәм/яки башкарылган эшләрне һәм төзелеш материалларын/эшләнмәләрен башка төр тәҗрибәләргә дучар итү таләп ителгән тикшерүләрне үткәргәндә Инспекциянең Инспекция структурасына караган Экспертизалар, тикшеренүләр һәм тәҗрибәләр үткәрүне күзәтү буенча территориаль органы (алга таба – Экспертизалар үткәрүне күзәтү буенча территориаль орган) җәлеп ителә.

Экспертизаларны үткәрүне күзәтү буенча территориаль орган тарафыннан бәя кую, яисә үз көче белән лаборатор-инструменталь контрольлек итү, шулай ук төрле экспертизалар үткәрү мөмкинлеге булмаганда, законнарда каралган тәртиптә, экспертлар һәм эксперт оешмалары җәлеп ителә.

Тиешле мәгълүматны бердәм тикшерүләр реестрына (алга таба – БТР) кертү 2008 елның 26 декабрендәге "Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшмәкәрләрнең хокукларын яклау турында" № 294-ФЗ Федераль законның 13.3 статьясы һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2015 елның 28 апрелендәге "Бердәм тикшерүләр реестрын формалаштыру һәм алып бару кагыйдәләре турында" № 415 карары (алга таба – РФ Хөкүмәтенең № 415 карары) нигезендә Инспекциядәге вәкаләт бирелгән вазифаи затлар тарафыннан башкарыла.

Дәүләт вазифаисы үтәлешен җайга сала торган норматив-хокукый актлар исемлеге

1.3. Дәүләт төзелеш күзәтчелеге түбәндәгеләр нигезендә тормышка ашырыла:

Россия Федерациясенең Административ хокук бозулар турында кодексы (алга таба – РФ КоАП) (Россия Федерациясенең Законнар җыелмасы, 2002, № 1 ( 1б.), 1 ст.; кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Россия Федерациясенең Арбитраж процессуаль кодексы (Россия Федерациясенең Законнар җыелмасы, 2002, № 30, 3012 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Россия Федерациясенең Шәһәр төзелеше кодексы (алга таба – РФ ШрК) (Россия Федерациясенең Законнар җыелмасы, 2005, № 1 (1 б.), 16 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

1995 елның 24 ноябрендәге "Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында" № 181-ФЗ Федераль закон (Россия Федерациясенең Законнар җыелмасы, 1995, №48, 4563 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

1999 елның 30 декабрендәге "Халыкның санитар-эпидемиологик иминлеге турында" № 52-ФЗ Федераль закон (Россия Федерациясенең Законнар җыелмасы, 1999, № 14, 1650 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

2002 елның 25 июнендәге "Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни ядкәрләре) турында" № 73 Федераль закон (алга таба - № 73 Федераль закон) (Россия Федерациясенең Законнар җыелмасы, 2002, №26, 2519 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

2002 елның 27 декабрендәге "Техник җайга салу турында" № 184-ФЗ Федераль закон (Россия Федерациясенең Законнар җыелмасы, 2002, N 52 (1б.), 5140 ст., 2005, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

2004 елның 27 июлендәге "Россия Федерациясендә дәүләт гражданлык хезмәте турында" № 79-ФЗ Федераль закон (Россия Федерациясенең Законнар җыелмасы, 2004, № 31, 3215 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

2006 елның 2 маендагы "Россия Федерациясе гражданнарының мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында" № 59-ФЗ Федераль закон (алга таба – №

59-ФЗ Федераль закон) (Россия Федерациясенең Законнар җыелмасы, 2006, № 19, 2060, 2010 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

2008 елның 22 июлендәге "Янгын куркынычсызлыгы таләпләре турында техник регламент" № 123-ФЗ Федераль закон (Россия Федерациясенең Законнар җыелмасы, 2008, №30 (1 бүлек), 3579 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

2008 елның 26 декабрендәге "Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшмәкәрләрнең хокукларын яклау турында" № 294-ФЗ Федераль закон (алга таба - № 294-ФЗ Федераль закон) (Россия Федерациясенең Законнар җыелмасы, 2008, №52 (1 б.), 6249 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

2009 елның 23 ноябрендәге "Энергияне саклау турында һәм энергия нәтиҗәлелеген арттыру турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында" № 261-ФЗ Федераль закон (алга таба – № 261-ФЗ Федераль закон) (Россия Федерациясенең Законнар җыелмасы, 2009, № 48, 5711 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

2009 елның 30 декабрендәге "Биналарның һәм корылмаларның куркынычсызлыгы турында техник регламент" № 384-ФЗ Федераль закон (алга таба – № 384-ФЗ Федераль закон) (Россия Федерациясенең Законнар җыелмасы, 2010, №1, 5 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2006 елның 1 февралендәге "Россия Федерациясендә дәүләт төзелеш күзәтчелеге турында" № 54 карары (алга таба – РФ Хөкүмәтенең № 54 карары) (Россия Федерациясенең Законнар җыелмасы, 2006, №7, 774 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2010 елның 21 июнендәге "Капиталь төзелеш объектларын төзегәндә, үзгәртеп корганда һәм капиталь ремонтлаганда төзелеш күзәтчелеген үткәрү тәртибе турында" № 468 карары (Россия Федерациясенең Законнар җыелмасы, 2010, №26, 3365 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2014 елның 26 декабрендәге "Аларны куллану нәтиҗәсендә "Биналарның һәм корылмаларның куркынычсызлыгы турында техник регламент" Федераль законы таләпләренең үтәлеше зарури нигездә тәэмин ителә торган илкүләм стандартларның һәм кагыйдәләр җыелмасының (мондый стандартларның һәм кагыйдәләр җыелмасының өлешләренең) исемлеген раслау хакында" № 1521 карары (Россия Федерациясенең Законнар җыелмасы, 2015, №2, 465 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Экологик, технологик һәм атом күзәтчелеге буенча федераль хезмәтнең 2006 елның 26 декабрендәге "Капиталь төзелеш объектларының төзелеше, үзгәртеп корылышы, капиталь төзеклəндерелешендәге башкарма документларның составына һәм аларны алып бару тәртибенә карата таләпләрне һәм эшләрне, конструкцияләрне, инженерлык-техник тәэмин ителеш челтәрләре өлешләрен таныклау актларына карата белдерелә торган таләпләрне раслау һәм кулланылышка кертү турында" №1128 боерыгы (РФ Юстиция министрлыгында 06.03.2007, № 9050 белән теркәлгән) (алга таба – Ростехнадзорның 26.12.2006 № 1128 боерыгы) ("Федераль башкарма хакимият органнарының норматив актлар бюллетене", 2007, № 13, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Экологик, технологик һәм атом күзәтчелеге буенча федераль хезмәтнең 2006 елның 26 декабрендәге “Дәүләт төзелеш күзәтчелеген тормышка ашырганда тикшерүләр үткәрү һәм төзелгән, үзгәртеп корылган, төзекләндерелгән капиталь төзелеш объектларының техник регламентларның (нормаларның һәм кагыйдәләрнең), башка төр норматив актларның, проект документларының таләпләренә ярашуы турындагы бәяләмәләрне бирү тәртибен раслау һәм гамәлгә кертү турында” № 1129 боерыгы (РФ Юстиция министрлыгында 06.03.2007, №9053 белән теркәлгән) (алга таба – Ростехнадзорның 26.12.2006, №1129 боерыгы) (“Федераль башкарма хакимият органнарының норматив актлар бюллетене”, 2007, № 15, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Экологик, технологик һәм атом күзәтчелеге буенча федераль хезмәтнең 2006 елның 26 декабрендәге “Дәүләт төзелеш күзәтчелеген тормышка ашырганда эшләрне рәсмиләштерү һәм алып бару тәртибен раслау һәм гамәлгә кертү турында” № 1130 боерыгы (РФ Юстиция министрлыгында 05.03.2007, № 9009 белән теркәлгән) (алга таба – Ростехнадзорның 26.12.2006 № 1130 боерыгы) (“Федераль башкарма хакимият органнарының норматив актлар бюллетене”, 2007, № 13 кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Экологик, технологик һәм атом күзәтчелеге буенча федераль хезмәтнең 2007 елның 12 гыйнварындагы “Капиталь төзелеш объектларының төзелеше, үзгәртеп корылышы, капиталь төзекләндерелеше барышында башкарылган эшләрне исәпкә алуның гомуми һәм (яисә) махсус журналын алып бару тәртибен раслау һәм гамәлгә кертү турында” № 7 боерыгы (РФ Юстиция министрлыгында 06.03.2007, № 9051 белән теркәлгән) (алга таба – Ростехнадзорның 12.01.2007, № 7 боерыгы) (“Федераль башкарма хакимият органнарының норматив актлар бюллетене”, 2007, № 14);

Россия Федерациясе Икътисади үсеш министрлыгының 2009 елның 30 апрелендәге “Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне тормышка ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшмәкәрләрнең хокукларын яклау турында” Федераль закон нигезләмәләрен тормышка ашыру турында” № 141 карары (РФ Юстиция министрлыгында 13.05.2009, № 13915 белән теркәлгән) (алга таба – Икътисади үсеш министрлыгының 30.04.2009 № 141 карары) (“Российская газета”, 2009, 14 май, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

РФ Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының 2015 елның 19 февралендәге “Төзелешкә рөхсәт рәвешен һәм объектны эксплуатациягә кертүгә рөхсәт рәвешен раслау турында” № 117/пр боерыгы (алга таба – Россия Төзелеш министрлыгының 19.02.2015 № 117/пр боерыгы) (Россия Федерациясенең Законнар җыелмасы, 2013, № 47, 6117 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Техник җайга салу һәм метрология буенча федераль агентлыкның 2015 елның 30 мартындагы “Стандартлаштыру өлкәсендә аларны куллану нәтиҗәсендә 2009 елның 30 декабрендәге “Биналарның һәм корылмаларның куркынычсызлыгы турында техник регламент” № 384-ФЗ Федераль закон таләпләренең ирекле нигездә үтәлеше тәэмин итела торган документлар исемлеген раслау хакында” № 365 боерыгы; (Норматив, методик һәм типик проект документациясе турында мәгълүмати бюллетень, 2015, № 5, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 елның 12 ноябрендәге “Татарстан Республикасы Дәүләт төзелешен күзәтү инспекциясе мәсьәләләре” № 622 карары (“Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының карарлары һәм әмернамәләре һәм республика башкарма хакимияте органнарының норматив актлары җыентыгы”, 2007, № 43, 1707 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 елның 31 декабрендәге “Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт вазифалары үтәлешенең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында” № 1192 карары (“Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының карарлары һәм әмернамәләре һәм республика башкарма хакимияте органнарының норматив актлары җыентыгы” журналы, 2013, №7, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2011 елның 24 июнендәге “Аларны төзү өчен төзелешкә рөхсәтләр бирү таләп ителми торган объектлар исемлеген раслау турында” № 1038-р әмернамәсе (“Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының карарлары һәм әмернамәләре һәм республика башкарма хакимияте органнарының норматив актлары җыентыгы” журналы, 2011, № 33, 1617 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып).

Дәүләт төзелеш күзәтчелегенә тиешле булган объектлар

1.4. Дәүләт төзелеш күзәтчелеге түбәндәгеләр очрагында гамәлгә ашырыла:

проект документлары РФ ШрК 49 статьясы нигезендә экспертизага (дәүләти яки дәүләти булмаган) тиешле булган яисә типик проект документлары яки аның уңай экспертиза (дәүләти яки дәүләти булмаган) бәяләмәсе алынган модификациясе булган капиталь төзелеш объектларын төзегәндә, РФ ШрК 54 статьясының 3 өлешендә күрсәтелгән объектлардан кала;

капиталь төзелеш объектларын үзгәртеп корганда, шул исәптән төбәк һәм җирле әһәмияттәге мәдәни мирас объектларын саклау буенча мондый объектларның ышанычлылыгы һәм куркынычсызлыгы буенча конструктив һәм башка сыйфатламаларына кагыла торган эшләрне үткәргәндә, әгәр дә капиталь төзелеш объектларын үзгәртеп коруга, шул исәптән мәдәни мирас объектларын саклау буенча аталган эшләргә карата проект документлары РФ ШрК 49 статьясы нигезендә экспертизага (дәүләти яки дәүләти булмаган) тиешле булса, РФ ШрК 54 статьясының 3 өлешендә күрсәтелгән объектлардан кала.

Дәүләт төзелеш күзәтчелегенең предметы

1.5. Дәүләт төзелеш күзәтчелеге тикшерүләр рәвешендә үткәрелә.

1.6. Дәүләт төзелеш күзәтчелегенең предметы:

1) капиталь төзелеш объектының төзелеше, үзгәртеп корылышы процессында башкарылган эшләрнең һәм кулланылган төзелеш материалларының, шулай ук мондый эшләрнең нәтиҗәләренең техник регламентлар, проект документлары, шул исәптән энергия нәтиҗәлелеге һәм капиталь төзелеш объектының энергия

ресурсларын исәпләү буенча кулланыла торган җайланмалар белән тәэмин ителеше таләпләренә җавап бирүе;

2) төзелешкә рөхсәт кәгазенең булуы;

3) түбәндәге таләпләрнең үтәлеше, алар нигезендә:

а) капиталь төзелеш объектларын төзү, үзгәртеп кору буенча капиталь төзелеш объектларының куркынычсызлыгына йогынты ясаучы эш төрләре бары тик үзеннән-үзе җайга салынулы оешма тарафыннан мондый эш төрләренә кертелү турында бирелгән таныклыкка ия булучы шәхси эшмәкәрләр яисә юридик затлар тарафыннан гына башкарылырга тиеш; капиталь төзелеш объектын төзү, үзгәртеп кору буенча башка төрле эшләр теләсә нинди физик яки юридик затлар тарафыннан башкарыла ала;

б) капиталь төзелеш объектын төзүче, үзгәртеп коручы зат (алга таба – төзүне башкаручы зат) булып төзүче яки төзүче яки техник заказчы тарафыннан шартнамә рәвешендә җәлеп ителүче физик яки юридик зат торырга мөмкин; төзүне башкаручы зат капиталь төзелеш объектын төзү, үзгәртеп кору буенча эшләрне оештыра һәм координацияли, күрсәтелгән эшләр барышында проект документларындагы, техник регламентлардагы, куркынычсызлык техникасындагы таләпләрнең үтәлешен тәэмин итә һәм башкарылган эшләрнең сыйфаты белән аларның проект документларындагы таләпләргә җавап бирүе өчен җаваплы була; төзүне башкаручы зат, мондый зат шушы пунктның 3 пунктчасындагы “а” пункт өлешендә каралган таләпләргә җавап биргән очракта, мөстәкыйль һәм (яки) шушы таләпләргә җавап бирүче башка затларны җәлеп итеп капиталь төзелеш объектын төзү, үзгәртеп кору буенча билгеле бер эшләрне башкарырга хокуклы.

Техник регламентлар булмаган очракта, башкарылган эшләрнең, кулланылган төзелеш материалларының һәм мондый эшләрнең нәтиҗәләренең төзелеш нормаларына һәм кагыйдәләренә, санитария-эпидемиология кагыйдәләренә һәм нормативларга, янгын куркынычсызлыгы таләпләренә, әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендәге таләпләргә, энергия нәтиҗәлелегенә кагылышлы таләпләргә һәм капиталь төзелеш объектының энергия ресурсларын исәпләү өчен кулланылучы җайланмалар белән тәэмин ителешенә кагылышлы таләпләргә, мәдәни мирас объектларын дәүләт тарафыннан саклау таләпләренә һәм мәдәни мирас объектларын саклау таләпләренә, сәнәгать куркынычсызлыгы таләпләренә, гидротехника корылмаларының куркынычсызлыгы нормаларына һәм кагыйдәләренә, башка төр иминлек кагыйдәләренә һәм дәүләт стандартларына, шулай ук Россия Федерациясенең норматив-хокукый актларындагы башка таләпләргә һәм башкарма хакимият органнарының капиталь төзелеш объектының төзелеше, үзгәртеп корылышы барышында зарури башкарылырга тиешле норматив-хокукый актларына (алга таба – нормалар һәм кагыйдәләр) җавап бирүен күзәтү дәүләт төзелешен күзәтүнең предметы булып тора.

Шушы Регламентта кулланыла торган “төзүче”, “техник заказчы”, “төзүне башкаручы зат” төшенчәләре һәм “юридик зат”, “шәхси эшмәкәр” төшенчәләре тигез мәгънәгә ия.

### Дәүләт төзелеш күзәтчелеген башкарганда вазифаи затларның бурычлары, вазифаи затлар өчен чикләмәләр

1.7. Вазифаи затларның дәүләт төзелеш күзәтчелеген башкарганда хокуклары:

1) хезмәт вазифаларын башкарганда капиталь төзелеш объектларына киртәләрсез үтеп керергә;

2) төзүчедән, техник заказчыдан яисә төзүне башкаручы заттан башкарылган эшләрнең нәтиҗәләрен, башкарма документларын, гомуми һәм (яки) махсус журналларны, эшләрне, конструкцияләрне, инженерлык-техник тәэмин ителеш челтәрләре урыннарын, кулланылучы төзелеш материалларының үрнәкләрен (пробаларын) таләп итәргә;

3) төзелеш контролен башкарганда таләп ителсә, әмма башкарылмаган булса, төзүчедән, техник заказчыдан яисә төзүне башкаручы заттан эшләнгән эшләргә һәм кулланылучы төзелеш материалларына карата тикшеренүләр, тәҗрибәләр, экспертизалар үткәрүне таләп итәргә;

4) төзүче, техник заказчы яисә төзүне башкаручы зат тарафыннан төзелеш контролен үткәрү, төзелеш контролен үткәргәндә һәм дәүләт төзелеш күзәтчелеген гамәлгә ашырганда башкарылган таләпләрнең техник регламентларның, башка төрле норматив-хокукый актларның һәм проект документларының таләпләренә җавап бирүе буенча ачыкланган җитешсезлекләрне юкка чыгару тәртибенең үтәлешен, шулай ук мондый җитешсезлекләрне юкка чыгару турындагы актларны төзегәнчегә кадәр эшләрне дәвам иттерүгә керешү чикләмәсен үтәвен тикшерергә;

5) тикшерүләрне үткәрү барышында, зарури таләпләрне, административ хокук бозу билгеләре булган очракта, фото, видео, кинотасмаларга төшерергә, ачыкланган хокук бозуларның дәлилләрен теркәү буенча башка билгеләнгән ысуллардан файдаланырга;

6) үткәрелгән тикшерүләрнең нәтиҗәләре буенча актлар төзергә, алар нигезендә ачыкланган бозуларны юкка чыгару турында күрсәтмәләр бирергә;

7) административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә һәм (яки) административ хокук бозу эшләрен карарга, Россия Федерациясенең административ хокук бозулар буенча законнарында каралган тәртиптә һәм очракларда административ хокук бозулар турындагы законнарында каралган тәртиптә һәм очракларда административ хокук бозу эшләре буенча эшләрнең үтәлешен тәэмин итү чараларын күрергә;

8) төзүчедән, техник заказчыдан яисә төзүне башкаручы заттан төзелешне башкару өчен җәлеп ителгән затлар белән шартланмәләрне, капиталь төзелеш объектларының куркынычсызлыгына йогынты ясый торган билгеле бер эш төренә яки эш төрләренә кертелү турында таныклыкны таләп итәргә;

9) төзүчедән, техник заказчыдан яисә төзүне башкаручы заттан, аларның вәкаләт бирелгән затларыннан тикшерү предметына карый торган мәсьәләләр буенча документларны һәм материлларны, шулай ук төзүченең, техник заказчының яки төзүне башкаручы затның җитәкчесеннән, аларның вәкаләт бирелгән затларыннан тикшерү предметына кагыла торган мәсьәләләр буенча язмача аңлатмалар соратып алырга;

10) түләүсез нигездә, шул исәптән электрон рәвештә Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән исемлеккә кертелгән документларны һәм (яки) материалларны әлеге документлар һәм (яки) мәгълүматлар белән эш итүче дәүләт органнарыннан,

җирле үзидарә органнарыннан яки дәүләт органнарының яки җирле үзидарә органнарының ведомство буйсынуындагы оешмалардан, ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында, Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән вакытларда һәм тәртиптә соратырга һәм алырга;

11) контрольдә тотучы, хокук саклаучы органнарга, судларга шәхси эшмәкәрләргә, юридик затларга карата тыкшынуны таләп итә торган, алар тарафыннан шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендәге законнарны бозу очраклары турында материалларны җибәрергә;

12) үткәрелгән тикшерүләрнең нәтиҗәләре хакында гомуми һәм (яки) махсус журналларга язулар теркәргә;

13) Россия Федерациясе законнарында каралган башка төрле вәкаләтләрне башкарырга.

1.8. Инспекциянең вәкаләтле вазифаи затларының дәүләт вазифасын башкаргандагы бурычлары:

1) Россия Федерациясе законнары нигезендә зарури үтәлергә тиешле таләпләр бозылуны кисәтү, ачыклау һәм юкка чыгару буенча билгеләнгән вәкаләтләрне үз вакытында һәм тулы күләмдә башкарырга;

2) Россия Федерациясе законнарын, дәүләт вазифасы башкарыла торган затларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен үтәргә;

3) Инспекция башлыгының (башлык урынбасарының) тикшерү үткәрү белән аны билгеләү турындагы боерыгы нигезендә тикшерүләр үткәрергә;

4) тикшерүне бары тик хезмәт вазифаларын башкарганда гына, урынга чыгып үткәрелә торган тикшерүне бары тик хезмәт таныклыкларын, Инспекция башлыгының, башлык урынбасарының әмернамәләре күчермәләрен күрсәткәндә генә һәм, шушы Регламентның 2.14 пунктының 2 пунктчасында каралган очракта, үткәреләчәк тикшерүне прокуратура органнары белән килештерү хакындагы документның күчермәсе күрсәтелгән очракта гына үткәрергә;

5) тикшерүне үткәргән вакытта юридик затның җитәкчесенә, башка вазифаи затына яисә вәкаләтле вәкиленә, шәхси эшмәкәргә, аның вәкаләтле вәкиленә тикшерүдә катнашу теләгенә каршы килмәскә һәм тикшерү предметына кагылышлы мәсьәләләр буенча аңлатмалар бирергә;

6) тикшерүне үткәргәндә катнашкан юридик затның җитәкчесенә, башка вазифаи затына яисә вәкаләтле вәкиленә, шәхси эшмәкәргә, аның вәкаләтле вәкиленә тикшерүнең предметына кагылышлы мәгълүматны һәм документларны бирергә.

7) юридик затның җитәкчесенә, башка вазифаи затына яисә вәкаләтле вәкиленә, шәхси эшмәкәргә, аның вәкаләтле вәкиленә тикшерү нәтиҗәләре хакында хәбәр итәргә;

8) юридик затның җитәкчесен, башка вазифаи затын яисә вәкаләтле вәкилен, шәхси эшмәкәрне, аның вәкаләтле вәкилен ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында алынган документлар һәм (яки) мәгълүмат белән таныштырырга;

9) ачыкланган бозу очраклары буенча күрелә торган чараларны билгеләгәндә, аталган чараларның бозуларның катлаулылыгына, аларның кешеләрнең гомеренә, сәламәтлегенә, хайваннарга, үсемлекләргә, әйләнә-тирә мохиткә, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларына (тарихи һәм мәдәни

ядкәрләренә), Россия Федерациясе Музей фонды составына кертелгән музей предметларына һәм музей коллекцияләренә, аеручы кыйммәтле, шул исәптән Россия Федерациясе Архив фондының уникаль документларына, махсус тарихи, фәнни, мәдәни әһәмияткә ия булган, илкүләм китапханә фонды составына керүче документларга, дәүләт иминлегенә, табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрнең килеп чыгышы өчен потенциаль куркынычының ни дәрәҗәдә катлаулы булуын исәпкә алырга, шулай ук гражданнарның, шул исәптән шәхси эшмәкәрләрнең, юридик затларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен нигезсез кысрыклауга юл куймаска;

10) юридик затлар, шәхси эшмәкәрләр тарафыннан шикаять ителгәндә, үз гамәлләренең урынлы башкарылуын Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә дәлилләргә;

11) № 294-ФЗ Федераль законда билгеләнгән тикшерү үткәрү вакытларын сакларга;

12) юридик заттан, шәхси эшмәкәрдән Россия Федерациясе законнарында каралмаган документларны һәм башка белешмәләрне таләп итмәскә;

13) тикшерү башланыр алдыннан юридик затның җитәкчесен, башка вазифаи затын яисә вәкаләтле вәкилен, шәхси эшмәкәрне, аның вәкаләтле вәкилен, аларның гозере буенча, шушы Регламент нигезләмәләре белән таныштырырга;

14) үткәрелгән тикшерүләрнең нәтиҗәләре турында тикшерүләрне исәпкә алу журналында, әгәр дә юридик затта, шәхси эшмәкәрдә ул булган очрака, шулай ук гомуми (махсус) журналда теркәргә;

15) үзеннән-үзе җайга салынулы оешмаларның әгъзаларын планнан тыш урынга чыгып тикшергәндә, аны үткәргән көнгә кадәр 3 эш көненнән дә соңга калмыйча үзеннән-үзе җайга салынулы оешмага, планнан тыш урынга чыгып тикшерү барышында аның вәкиле катнашуны тәэмин итү максатларында, планнан тыш урынга чыгып тикшерү булачагы турында хәбәр итәргә;

16) үзеннән-үзе җайга салынулы оешмаларның әгъзалары тарафыннан зарури таләпләрнең бозылу очракларын ачыклаган очракта, тикшерүне үткәргән көннән соң 5 эш көне дәвамында, үткәрелгән тикшерү барышында алынган һәм дәүләт, коммерция, хезмәт, башка төрле закон белән саклана торган серне тәшкил итүче мәгълүматларны тарату турындагы чикләмәләрне исәпкә алып, үзеннән-үзе җайга салынулы оешмага ачыкланган бозу очраклары турында белешмәләр җибәрергә;

17) Инспекция тарафыннан чыгарылган, административ хокук бозу эшләре буенча карарларның үтәлешен раслый торган документларны тикшерергә.

1.9. Инспекциядәге вазифаи затлар хокуклы түгел:

1) зарури таләпләрнең һәм муниципаль-хокукый актларда билгеләнгән таләпләрнең үтәлешен тикшерергә, әгәр дә мондый таләпләр Инспекция вәкаләтләренә карамаса;

2) СССР һәм РСФСР башкарма хакимияте органнарының норматив-хокукый актларында билгеләнгән һәм Россия Федерациясенең гамәлдәге законнарына туры килми торган таләпләрнең үтәлешен тикшерергә;

3) Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгарылмаган зарури таләпләрнең һәм муниципаль-хокукый актларда билгеләнгән таләпләрнең үтәлешен тикшерергә;

4) аны үткәргәндә юридик затның җитәкчесе, башка вазифаи заты яки вәкаләтле вәкиле, шәхси эшмәкәр, аның вәкаләтле вәкиле булмаган очракта урынга чыгып тикшерү үткәрергә, мондый тикшерү капиталь төзелеш объектын төзегәндә, үзгәртеп корганда эшләр башкару барышында барлыкка килгән авария, техник регламентларны, башка төрле норматив-хокукый актларны һәм проект документларын бозу очраклары, кулланыла торган төзелеш материалларына карата зарури таләпләрнең бозылу очраклары буенча үткәрелгән очрактан кала, әгәр дә мондый бозу очраклары кешеләрнең гомеренә, сәламәтлегенә, әйләнә-тирә мохиткә, дәүләт иминлегенә, физик һәм юридик затларның мөлкәтенә, дәүләти яки муниципаль милеккә зыян салса яисә мондый зыян салынуга сәбәпче булса;

5) документларны, мәгълүматларны, продукциянең үрнәкләрен, әйләнә-тирә мохит объектларын һәм житештерү мохите объектларын тикшерү пробаларын таләп итәргә, әгәр дә алар тикшерү объектлары булып саналмаса яки тикшерү предметына карамаса, шулай ук мондый документларның төп нөсхәләрен тартып алырга;

6) продукциянең үрнәкләрен, әйләнә-тирә мохит объектларын һәм җитештерү мохите объектларын тикшерү пробаларын аталган үрнәкләрне, пробаларны сайлап алу турындагы беркетмәләрне рәсмиләштермичә һәм бу үрнәкләрне, пробаларны илкүләм стандартларда, үрнәкләрне, пробаларны сайлап алу кагыйдәләрендә һәм аларны тикшерү, сынау, үлчәүләр ысуллары белән, техник регламентлар яки алар гамәлгә кергән көнгә кадәр гамәлдә булган башка төрле норматив-техник документлар һәм кагыйдәләр һәм тикшеренүләр, сынаулар, үлчәүләр ысуллары белән билгеләнгән нормаларны артып киткән күләмдә сайлап алырга;

7) тикшерү барышында алынган һәм дәүләт, коммерция, хезмәт, закон белән саклана торган башка серне тәшкил итүче мәгълүматларны таратырга, Россия Федерациясе законнарында каралган очраклардан тыш;

8) тикшерүне үткәрүнең билгеләнгән срокларын арттырырга;

9) юридик затларга, шәхси эшмәкәрләргә алар хисабыннан контрольлек буенча чаралар үткәрү турында күрсәтмәләр яки тәкъдимнәр бирергә;

10) юридик заттан, шәхси эшмәкәрдән, башка төрле дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары яки дәүләт органнарының яки җирле үзидарә органнарының ведомство буйсынуындагы оешмалар эш итә торган рөхсәт документларын кертеп, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең билгеле бер исемлегенә кертелгән документларны һәм (яки) мәгълүматны таләп итәргә;

11) юридик заттан, шәхси эшмәкәрдән Россия Федерациясе законнарындагы таләпләр нигезендә элегрәк тапшырылган һәм (яки) дәүләти яки муниципаль мәгълүмат системаларында, реестрларда һәм регистрларда булган мәгълүматны тапшыруны таләп итәргә.

## Аларга карата дәүләт төзелеш күзәтчелеге башкарыла торган затларның хокуклары һәм бурычлары

1.10. Аларга карата дәүләт төзелеш күзәтчелеге башкарыла торган юридик затларның җитәкчеләре, бүтән вазифаи затлары яки вәкаләт бирелгән затлары, шәхси эшмәкәрләр, аларның вәкаләтле вәкилләре түбәндәгеләргә хокуклы:

1) тикшерү үткәрелгәндә турыдан-туры катнашырга, тикшерү предметына кагылышлы мәсьәләләргә аңлатмалар бирергә.

2) Инспекциянең тикшерү үткәрүче вазифаи затларыннан тикшерү предметына кагылышлы һәм аның бирелеше гамәлдәге законнарда каралган мәгълүматны алырга.

3) Инспекция тарафыннан ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында шушы документлар һәм (яки) мәгълүматлар белән эш итүче башка дәүләт органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан яисә дәүләт органнарының яки җирле үзидарә органнарының ведомство буйсынуындагы оешмалардан алынган документлар һәм (яки) мәгълүматлар белән танышырга;

4) ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында сорала торган документларны һәм (яки) мәгълүматларны Инспекциягә шәхси ихтыяры буенча тапшырырга;

5) тикшерү нәтиҗәләре белән танышырга һәм тикшерү актында үзенең тикшерү нәтиҗәләре белән танышуы, алар белән, шулай ук Инспекциядәге вазифаи затларның гамәлләре белән килешүе яки килешмәве турында күрсәтергә;

6) тикшерүне үткәргәндә Инспекциядәге вазифаи затларның юридик затның, шәхси эшмәкәрнең хокуклары бозылуга китергән гамәлләрен (гамәл кылмауларын) Россия Федерациясе законнары нигезендә административ һәм (яки) суд тәртибендә шикаять кылырга;

7) эшмәкәрләрнең хокукларын яклау буенча Россия Федерациясе Президенты карамагындагы Вәкаләтле вәкилне яки эшмәкәрләрнең хокукларын яклау буенча Татарстан Республикасы Президенты карамагындагы Вәкаләтле вәкилне тикшерүдә катнашу өчен җәлеп итәргә;

8) тикшерү актында бәян ителгән фактлар, нәтиҗәләр, тәкъдимнәр белән, яисә ачыкланган җитешсезлекләрне юкка чыгару турында бирелгән күрсәтмәләр белән риза булмаган очракта, тикшерү актын алган датадан соң унбиш көн дәвамында Инспекциягә язмача рәвештә тикшерү актына һәм (яки) ачыкланган җитешсезлекләрне юкка чыгару турында бирелгән күрсәтмәгә тулаем яки аның аерым җөмләләренә карата ризасызлык тапшырырга; мондый ризасызлыкларга аларның нигезле булуын раслый торган документларны яки аларның таныкланган күчермәләрен теркәргә яисә килештерелгән чорда аларны Инспекциягә тапшырырга; аталган документлар тикшерелә торган затның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзаланган электрон документлар (электрон документлар җыелмасы) рәвешендә булырга мөмкин;

9) РФ Икътисади үсеш министрлыгының № 141 боерыгы белән расланган үрнәк рәвешендә тикшерүләрне исәпкә алу журналын алып барырга

1.11. Аларга карата дәүләт төзелеш күзәтчелеге башкарыла торган юридик затларның һәм шәхси эшмәкәрләрнең бурычлары:

1) Инспекциядәге вазифаи затларны капиталь төзелеш объектына кертергә;

2) Инспекциядәге вазифаи затларга тикшерүне үткәрүнең максатларына һәм бурычларына ирешү өчен кирәкле булган документларны тапшырырга;

3) тикшерү үткәрүдән качмаска;

4) төзелеш контролен үткәрергә;

5) башкарма документларны алып баруны тәэмин итәргә;

6) тикшерүне үткәргәндә кирәкле аңлатмаларны бирергә, барлыкка килгән мәсьәләләр буенча белешмәләр тапшырырга;

7) төзелеш контролен үткәргәндә һәм дәүләт төзелеш күзәтчелеген башкарганда ачыкланган җитешсезлекләрне юкка чыгаруны тәэмин итәргә һәм мондый җитешсезлекләрне юкка чыгару турында актлар төзелгәнчегә кадәр эшләрне дәвам иттерүгә керешмәскә;

8) кулланыла торган төзелеш материалларының сыйфаты буенча контрольлек булдырырга;

9) Инспекциядәге вазифаи затларның Россия Федерациясе законнарында каралган үз вәкаләтләрен үтәү өчен шартлар тәэмин итәргә;

10) тикшерүгә тиешле эшләр тәгәлләнүнең тикшерүлзәрне үткәрү программасында күрсәтелгән чорлары үзгәрү турында Инспекциягә хәбәр итәргә; капиталь төзелеш объектын төзегәндә, үзгәртеп корганда барлыкка килүче һәр авария очрагы турында хәбәрнамә җибәрергә;

11) Инспекция таләбе буенча Россия Федерациясе законнары кысаларында башкарылган эшләрнең нәтиҗәләре турында мәгълүмат һәм башка белешмәләр тапшырырга;

12) төзүче, техник заказчы булган юридик затлар, шәхси эшмәкәрләр шулай ук ук түбәндәгеләрне тиешле:

- төзелешне башкаручы затларга тикшерүләрне үткәрү программасында каралган тикшерүләр турында белешмәләр җиткерергә;

- Инспекциягә төзелешне, үзгәртеп коруны башлау турында хәбәрнамә тапшырганда белдерелгән белешмәләрнең үзгәрүе турында билгеләнгән тәртиптә хәбәр итәргә;

- капиталь төзелеш объектын шартнамә нигезендә төзегәндә, үзгәртеп корганда эшләр башкарылу барышында төзелеш контрольлеген гамәлгә ашыруны тәэмин итәргә;

- эшләрне туктату зарурлыгы килеп туган очракта яки аларны алты айдан артып китә торган чорга туктатып торганда капиталь төзелеш объектын консервацияләргә һәм объектны консервацияләү турында карар кабул ителгәннән соң 10 календарь көне эчендә бу хакта Инспекциягә хәбәр итәргә;

- алдан ук, объектны төзи (үзгәртеп кора) башлаганчыга (эшләрне торгызганчыга) кадәр 7 эш көненнән дә соңга калмыйча объектны төзи (үзгәртеп кора) башлау (эшләрне торгызу) турында Инспекциягә хәбәр итәргә, әгәр дә капиталь төзелеш объектын төзү (үзгәртеп кору) дәүләт төзелеш күзәтчелегенә тиешле булса;

13) төзүче, техник заказчы, төзүне башкаручы зат Россия Федерациясе законнары нигезендә бүтән бурычларга да ия булырга мөмкин.

## Дәүләт төзелеш күзәтчелеген башкару нәтиҗәләре

1.12. Дәүләт төзелеш күзәтчелеген башкару нәтиҗәләре:

1) 2 нөсхәдә рәсмиләштерелгән тикшерү акты;

2) урынга чыгып үткәрелгән тикшерү турында тикшерүләр журналында (булган очракта), шулай ук гомуми (махсус) журналда теркәлгән язу;

3) № 294-ФЗ Федераль законның 13.3 статьясы һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең № 415 карары нигезендә БТР кертелгән тиешле мәгълүмат;

зарури таләпләрне бозу очраклары ачыкланганда:

4) тикшерү актына кушымта була торган, зарури таләпләрне бозу буенча ачыкланган очракларны юкка чыгару турында күрсәтмә (алга таба – күрсәтмә);

5) РФ КоАП каралган административ хокук бозу турында беркетмә.

Дәүләт төзелеш күзәтчелеген башкару нәтиҗәләре буенча төзүчегә (техник заказчыга) төзелгән, үзгәртеп корылган капиталь төзелеш объектының техник регламентларның, проект документларының таләпләренә, шул исәптән капиталь төзелеш объектының энергетик нәтиҗәлелеге таләпләренә һәм кулланылучы энергетика ресурсларын исәпкә алы җайланмалары белән тәэмин ителеше таләпләренә җавап бирү турында бәяләмә (алга таба – Ярашлылык турында бәяләмә) бирелә.

## 2. Дәүләт төзелеш күзәтчелеген тормышка ашыру тәртибенә карата таләпләр

Дәүләт төзелеш күзәтчелеген тормышка ашыру турында мәгълүматлаштыру тәртибе

2.1. Инспекциянең урнашу урыны: 420111, Казан ш., З. Кызыл ур., 15/9 й..

2.2. Инспекциягә дәүләт төзелеш күзәтчелеген тормышка ашыру мәсьәләләре буенча документлар һәм мөрәҗәгатьләр юллау өчен почта адресы: 420111, Казан ш., З. Кызыл ур., 15/9 й..

2.3. Инспекциянең эш графигы: дүшәмбе-пәнҗешәмбе 8.30 сәгатьтән 17.30 сәгатькә кадәр, җомга 08.30 сәгатьтән 16.30 сәгатькә кадәр, төшке аш - 12.00 сәгатьтән 12.45 сәгатькә кадәр, шимбә һәм якшәмбе – ял көннәре.

2.4. Белешмә телефоннары: 237-19-87, 237-97-53.

2.5. Инспекциянең территориаль органнарының адреслары һәм телефоннары 1 таблицада китерелде.

1 таблица – Территориаль органнар турында белешмәләр

| Территориаль орган | Адресы | Телефоны |
|---|---|---|
| Автоюллар һәм юл буе төзелешен күзәтү буенча территориаль орган | Казан ш., Декабристлар ур., 81 | (843) 518-81-60 |
| Капиталь төзелеш объектларының төзелешен, үзгәртеп корылышын күзәтү буенча өлкәара орган | Казан ш., Декабристлар ур, 81 | (843) 518-83-44 |
| Капиталь төзелеш объектларының төзелешен, үзгәртеп корылышын күзәтү | Лаеш ш., Ульянова ур., 54 | (84378) 2-55-03 |

| | | |
|---|---|---|
| буенча Төньяк-Көнбатыш территориаль орган | | |
| Капиталь төзелеш объектларының төзелешен, үзгәртеп корылышын күзәтү буенча Төньяк-Көнчыгыш территориаль орган | Чаллы ш., Госманов ур., 57а | (8552) 52-74-52 |
| Капиталь төзелеш объектларының төзелешен, үзгәртеп корылышын күзәтү буенча Көнчыгыш территориаль орган | Түбән Кама ш., Җиңүгә 30 ел ур., 7й. | (8555) 30-15-31 |
| Капиталь төзелеш объектларының төзелешен, үзгәртеп корылышын күзәтү буенча Кама арты территориаль орган | Чистай ш., Толстой ур., 157 | (84342) 5-45-69 |
| Капиталь төзелеш объектларының төзелешен, үзгәртеп корылышын күзәтү буенча Көньяк-Көнчыгыш территориаль орган | Әлмәт ш., Шевченко ур., 62 | (8553) 45-80-83 |
| Капиталь төзелеш объектларының төзелешен, үзгәртеп корылышын күзәтү буенча Көнбатыш территориаль орган | Яшел Үзән ш., Норкин ур., 6 | 8 (84371) 47095 |
| Экспертизалар, тикшеренүләр һәм сынаулар үткәрүне күзәтү буенча территориаль орган | Казан ш., Декабристлар ур., 81 | (843) 518-81-60 |

2.6. Инспекциянең “Интернет” челтәрендәге рәсми сайты: htpp://gsn.tatarstan.ru. Электрон почта адресы: gsn@tatar.ru.

2.7. Дәүләт төзелеш күзәтчелеген тормышка ашыру мәсьәләләре буенча мәгълүмат түбәндәгечә җиткерелә:

телдән мөрәҗәгать буенча (шәхси яисә телефон аша);

язмача мөрәҗәгать буенча;

gsn@tatar.ru электрон почтасы аша килгән мөрәҗәгать буенча;

Инспекциянең рәсми интернет-сайтында урнаштыру юлы белән;

Инспекция аппараты һәм аның территориаль органнары биналарындагы мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән.

Телдән мөрәҗәгатькә җавап мөрәҗәгать иткәннән соң озакка сузмыйча бирелә, язмача һәм (яисә) электрон почта аша җибәрелгән мөрәҗәгатькә җавап, мондый мөрәҗәгатьнең Инспекциядә теркәлгән көненнән башлап 30 көннән дә артмаган срокта, юридик затның, шәхси эшмәкәрнең, физик затның почта адресына, яисә электрон почтасына җибәрелә.

Инспекциянең яисә аның территориаль органнарының шалтыратуны кабул иткән вазифаи заты куелган сорауларга җавап бирә алмаса, телефоннан сөйләшү башка вазифаи затка адреслана (тапшырыла) яисә мөрәҗәгать итүчегә кирәкле мәгълүматны алырга мөмкин булган телефон номеры әйтелә.

2.1.8. Инспекциянең мәгълүмат стендларында һәм http://gsn.tatarstan.ru рәсми интернет-сайтында түбәндәге мәгълүмати материаллар урнаштырыла:

дәүләт төзелешен күзәтүнең тәртибе турындагы мәгълүмат;

дәүләт төзелешен күзәтүне башкаруны көйләүче норматив-хокукый актлардан күчермәләр;

тутыру өчен документларның формалары.

Инспекциянең урнашу урыны, эш графигы, телефоннар һәм факс номеры, электрон почта адресы;

дәүләт вазифасын үтәү барышында тормышка ашырылучы гамәлләргә (гамәл кылмауларга) һәм карарларга карата шикаять бирү тәртибе;

дәүләт вазифасын үтәгәндә эшләрнең эзлеклелеген чагылдыручы блок-схема.

2.9. Инспекциянең интернет-сайтында Россия Федерациясе законнарында каралган мәгълүматлар урнаштырыла.

### Дәүләт контрольлеге (күзәтчелеге) буенча чараларны үткәргән өчен юридик затлардан, шәхси эшмәкәрләрдән түләү алуның ярамаганлыгы

2.10. Дәүләт төзелеш күзәтчелеге буенча чаралар үткәрүгә, шул исәптән, экспертларның һәм эксперт оешмаларының хезмәтләренә, тикшерү үткәрүгә аларны җәлеп иткән очракта, юридик затлардан һәм шәхси эшмәкәрләрдән түләү алынмый.

### Дәүләт вазифасын үтәү вакыты

2.11. Дәүләт вазифасы Инспекция тарафыннан эшләрнең башлануы турында хәбәр алынганнан соң төзүчегә яки техник заказчыга Ярашлылык турында бәяләмә биргән датага кадәр гамәлгә ашырыла.

2.12. Дәүләт вазифасы тикшерүләр рәвешендә гамәлгә ашырыла. Бер юридик затка карата яки шәхси эшмкәргә карата үткәрелә торган тикшерүнең вакыты егемре эш көненнән артык булырга тиеш түгел.

Искәрмәле, катлаулы һәм (яки) озын тикшеренүләрне, сынауларны, махсус экспертизаларны һәм тикшерүләрне үткәрүгә бәйле булган очракларда, Инспекциянең урынга чыгып тикшерү үткәрүче вазифаи затларының дәлилле

тәкъдимнәре нигезендә урынга чыгып үткәрелә торган тикшерүнең вакыты Инспекция башлыгы тарафыннан озынайтылырга мөмкин, ләкин егерме эш көненнән дә артыграк вакытка түгел.

Тикшерүләр үткәрүнең нигезе

2.13. Тикшерүләр планлы тикшерүләр үткәрүнең еллык планын формалаштырмыйча үткәрелә.

2.14. Тикшерүләрне үткәрү нигезләре:

1) төзүчедән, техник заказчыдан яисә төзүне башкаручы заттан РФ ШрК 52 статьясының 5 һәм 6 өлешләре нигезендә җибәрелгән хәбәрнамә, шулай ук җитешсезлекләрне юкка чыгару турында, капиталь төзелеш объектының төзелеше, үзгәртеп корылышы тәмамлану турында хәбәрнамә;

2) гражданнарның, шул исәптән шәхси эшмәкәрләрнең, юридик затларның мөрәҗәгатьләре һәм гаризалары, РФ ШрК 53 статьясының 3 өлеше нигезендә төзелеш башкаручы затлардан юллanучы хәбәрнамәләрне дә кертеп, дәүләт хакимияте органнарыннан (дәүләт күзәтчелеге органнарының вазифаи затларыннан), җирле үзидарә органнарыннан кергән мәгълүмат, РФ ШрК 53 статьясының 3 өлеше нигезендә төзүне башкаручы затлардан юлланучы хәбәрнамәләрне дә кертеп, капиталь төзелеш объектының төзелеше, үзгәртеп корылышы процессында эшләрне башкарганда килеп чыккан аварияләр, техник регламентларның, башка норматив-хокукый актларның һәм проект документларының, шул исәптән, әгәр дә мондый бозулар кешенең тормышына, сәламәтлегенә, әйләнә-тирә мохиткә, дәүләтнең иминлегенә, физик һәм юридик затларның мөлкәтенә, дәүләти һәм муниципаль мөлкәткә куркыныч тудырса яисә мондый зыян салынуга китерсә, кулланылучы төзелеш материалларына карата һичшиксез үтәлергә тиешле таләпләрнең бозылуы турындагы фактлар буенча, массакүләм мәгълүмат чараларыннан алынган мәгълүмат;

3) Инспекция тарафыннан эшләнгән тикшерүләр программасы;

4) юридик затларга, шәхси эшмәкәрләргә зарури таләпләрне бозу буенча ачыкланган җитешсезлекләрне юкка чыгару турында Инспекция биргән күрсәтмәнең вакыты бетү;

5) Инспекция башлыгының (башлык урынбасарларының) Россия Федерациясе Президенты яисә Россия Федерациясе Хөкүмәте кушуы буенча чыгарылган боерыкның (әмернамәнең) булуы яисә прокуратура органнарына килгән материаллар һәм мөрәҗәгатьләрнең үтәлешен күзәтү кысаларында прокурорның планнан тыш тикшерү үткәрүне таләп итүе нигезендә;

6) төзүчедән, техник заказчыдар, төзүне башкаручы заттан тикшерүгә тиешле эшләрне тәмамлау вакытларының үзгәрүе турында хәбәрнамә алынганда, әгәр дә мондый эшләрне тәмамлау вакыты тикшерүләрне үткәрү программасында күрсәтелгән вакытларга туры килмәсә.

Дәүләт төзелеш күзәтчелеген турыдан-туры гамәлгә ашыручы вазифаи затлар

2.15. Тикшерүләр турыдан-туры Инспекциядәге Инспекция башлыгының (башлык урынбасарының) билгеле бер капиталь төзелеш объектында дәүләт төзелеш күзәтчелеген башкаруга җаваплы затларны билгеләү турындагы тиешле боерыгы (әмернамәсе) (алга таба – вазифаи затларны билгеләү турындагы боерык), Инспекция башлыгының (башлык урынбасарының) тикшерүне үткәрү турындагы боерыгы (әмернамәсе) нигезендә вазифаи затлар тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Административ хокук бозу эшләре буенча беркетмәләр Регламентка карата 1 кушымтада күрсәтелгән вазифаи затлар тарафыннан төзелә.

Дәүләт төзелеш күзәтчелеге өлкәсендә Россия Федерациясе законнарын бозган өчен юридик затларның, шәхси эшмәкәрләрнең җаваплылыгы

2.16. Тикшерүләрне үткәрүгә нигезсез каршылык күрсәтүче, тикшерүләрне үткәрүдән качып йөрүче һәм (яки) зарури таләпләрне бозу буенча ачыкланган җитешсезлекләрне юкка чыгару буенча Инспекция күрсәтмәләрен билгеләнгән вакытка үтәмәүче юридик затлар, аларның җитәкчеләре, башка вазифаи затлары яисә юридик затларның вәкаләтле вәкилләре, шәхси эшмәкәрләр, аларның вәкаләтле вәкилләре Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплы була.

Дәүләт төзелеш күзәтчелеген башкарганда Инспекциянең һәм андагы вазифаи затларның җаваплылыгы

2.17. Инспекция, андагы вазифаи затлар тикшерүләрне үткәргәндә үз вазифаларын, хезмәт бурычларын тиешенчә башкармаганда, хокукка каршы килә торган гамәлләр кылганда (гамәл кылмаганда) Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплы була.

Россия Федерациясе законнарын бозучыларга карата күрелгән чаралар турында, мондый чаралар кабул ителгән көннән соң ун көн эчендә, хокуклары һәм (яки) законлы мәнфәгатьләре бозылган юридик затка, шәхси эшмәкәргә язмача рәвештә хәбәр ителә.

## 3. Юридик затларга, шәхси эшмәкәрләргә белдерелә торган зарури таләпләр

Юридик затларга, шәхси эшмәкәрләргә карата белдерелүче зарури таләпләрнең исемлеге, тиешле таләпне билгели торган норматив-хокукый актларны күрсәтеп, 2 таблицада күрсәтелде.

2 таблица – Юридик затларга һәм шәхси эшмәкәрләргә белдерелә торган зарури таләпләр исемлеге

| Контрольлек субъектлары | Зарури таләпнең тәгъбирләнеше | Зарури таләпне билгели торган норматив-хокукый акт |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| Төзүче, техник заказчы, төзүне башкаручы зат | 1.Төзелешкә рөхсәт булу | РФ ШрК 51 ст. 2 өл.; Россия Төзелеш министрлыгының 19.02.2015 №117/пр боерыгы |
| | 2. Инспекциягә тулы күләмдә, ә төзелешнең, үзгәртеп коруның аерым этабына рөхсәт бирелгән очракларда, тиешле төзелеш этабын башкару өчен кирәкле күләмдә проект документларын тапшыру | РФ ШРК 52 ст. 5 өл. |
| | 3. Проект документларына карата уңай экспертиза бәяләмәсе булу | РФ ШРК 52 ст. 5 өл. |
| | 4. Инспекциягә кызыл линияләрдән чигенеш линияләре җирлегенә чыгару турында документ тапшыру | РФ ШРК 52 ст. 5 өл. |
| | 5. Башкарылган эшләрне исәпкә алу алып барыла торган гомуми һәм махсус журналларны алып бару һәм саклау өчен Инспекциягә тапшыру | РФ ШРК 52 ст. 5 өл.;<br>РФ Хөкүмәтенең №54 карарының 24 п.;<br>Ростехнадзорның 12.01.2007 № 7 боерыгының 8 п., 10 п. |
| | 6. Үзеннән-үзе җайга салынулы оешма тарафыннан бирелгән, капиталь төзелеш объектын төзү, үзгәртеп кору буенча капиталь төзелеш объектларының куркынычсызлыгына йогынты ясый торган эш төрләренә кертелү турында таныклыкны Инспекциягә тапшыру. | РФ ШрК 52 ст. 2,3.1 өл., 55.8 ст. 4 өл.;<br>ТР МК № 622 карарының 4.1.3 п. |
| | 7. төзү, үзгәртеп кору өчен җәлеп ителгән затлар белән шартнамәләрне Инспекциягә тапшыру | РФ ШрК 52 ст. 5 өл.;<br>ТР МК № 622 карарының 4.1.3 п. |
| | 8. Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектын (тарихи һәм мәдәни ядкәрләрен) саклау буенча эшчәнлек башкаруга, шул исәптән | ч.6 ст.45 Федерального закона № 73-ФЗ |

| | | |
|---|---|---|
| | реставрация эшләрен башкаруга, мәдәни мирас объектын саклау буенча мондый объектның башка төрле ышанычлылык һәм куркынычсызлык сыйфатламалары-на кагыла торган эшләрне башкаруга лицензия булу | |
| | 9. Инспекциягә башкарылган эшләрнең нәтиҗәләрен, эшләрне, конструкцияләрне, инженерлык-техник тәэминат челтәрләре өлешләрен, кулланыла торган төзелеш материалларының үрнәкләрен (пробаларын) таныклау актларын тапшыру | РФ Хөкүмәтенең № 54 карарының 24 п. |
| | 10. Башкарма документны алып бару, саклау һәм Инспекциягә тапшыру | РФ ШрК 52 ст. 6 өл; РФ Хөкүмәтенең № 54 карарының 24п.; Ростехнадзорның 26.12.2006 № 1128 боерыгының 4 п., 5п. |
| | 11. Инспекциягә тикшерүгә тиешле эшләрне төгәлләү сроклары турында хәбәрнамә җибәрү, капиталь төзелеш объектын төзегәндә, үзгәртеп корганда | РФ ШрК 52 ст. 6 өл. |
| | 12. Инспекциягә капиталь төзелеш объектындагы һәр аварияле очракның барлыкка килүе турында хәбәр итәргә | РФ ШрК 53 ст. 3 өл., Ростехнадзорның 26.12.2006. № 1129 боерыгының 8 п. |
| | 13. Инспекциягә тикшерүгә тиешле эшләрнең тәмамлауны чорларын үзгәртү турында хәбәрнамә җибәрү, әгәр дә мондый эшләрне төгәлләү вакыты тикшерүләрне үткәрү программасында күрсәтелгән срокларга туры килмәсә | Ростехнадзорның 26.12.2006 г. № 1129 боерыгының 3 п., 8 п. |
| | 14. Инспекциягә капиталь төзелеш объектын төзегәндә, үзгәртеп корганда җибәрелгән җитешсезлекләрне юкка чыгару турында хәбәрнамә җибәрү | Ростехнадзорның 26.12.2006 № 1129 боерыгының 16 п. |
| | 15. Капиталь төзелеш объектын төзү, үзгәртеп кору буенча эшләрне оештыру һәм координацияләү, проект документларындагы, техник регламентлардагы, техник куркынычсызлык буенча таләпләрнең | РФ ШрК 52 ст. 3 өл. |

| | | |
|---|---|---|
| | күрсәтелгән эшләр барышында үтәлешен тәэмин итү, башкарылган эшләрнең сыйфаты һәм аларның проект документларындагы таләпләргә җавап җирүе өчен җаваплы булу | |
| | 16. Капиталь төзелеш объектын төзүченең яки техник заказчының (төзүне, үзгәртеп коруны шартнамә нигезендә башкарган очракта) биреме, проект документлары, җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планы таләпләре, техник регламентларның таләпләре нигезендә төзергә, үзгәртеп корырга, өченче затлар һәм әйләнә-тирәлек өчен эшләрнең куркынычсызлыгын, хезмәт куркынычсызлыгы таләпләренең үтәлешен, мәдәни мирас объектларының сакланышын тәэмин итү | РФ ШрК 52 ст. 6 өл. |
| | 17. Төзелеш контролен үткәрү | РФ ШрК 52 ст. 6 өл;<br>РФ ШрК 53 ст. 2 өл |
| | 18. Капиталь төзелеш объектының куркынычсызлыгына йогынты ясый торган һәм төзү, үзгәртеп кору технологиясе нигезендә аларны контрольдә тоту башка эшләрне башкарганнан соң мөмкин булмаган эшләрнең үтәлешенә, шулай ук, әгәр дә төзелеш контрольлеген үткәргәндә ачыкланган җитешсезлекләрне сүтмичә яисә башка төзелеш конструкцияләренә һәм инженерлык-техник тәэминат челтәрләренең өлешләренә зыян салмыйча юкка чыгару мөмкин булмаса, төзелеш конструкцияләренең һәм инженерлык-техник тәэминат челтәрләре өлешләренең иминлегенә һәм аталган эшләрнең, конструкцияләрнең һәм челтәр өлешләренең техник регламентлардагы һәм проект документларындагы таләпләргә туры килүенә контроль үткәрү. Аталган эшләрне, конструкцияләрне, инженерлык-техник тәэминат челтәрләре өлешләрен таныклау актларын төзү | РФ ШрК 52 ст.3 өл |

| | | |
|---|---|---|
| | 19. Капиталь төзелеш объектының куркынычсызлыгына йогынты ясый торган һәм төзү, үзгәртеп кору технологиясе нигезендә аларны контрольдә тоту башка эшләрне башкарганнан соң мөмкин булмаган барлык эшләрнең үтәлешенә контрольлек үткәрү, шулай ук, проект документларында, техник регламентлардагы таләпләр белән каралган очракларда, мондый конструкцияләргә сынаулар үткәрелергә тиеш. Аталган эшләрне, конструкцияләрне, инженерлык-техник тәэминат челтәрләре өлешләрен таныклау актларын төзү | РФ ШрК 52 ст. 3 өл. |
| | 20. Башкарылган эшләргә һәм кулланыла торган төзелеш материалларына тикшерүләр, сынаулар, экспертизалар үткәрү, әгәр дә ул төзелеш контрольлеген үткәргәндә таләп ителсә, ләкин башкарылмаган булса | РФ Хөкүмәтенең №54 карарының 24 п. |
| Төзүне башкаручы зат | 21. Капиталь төзелеш объектын төзү, үзгәртеп кору башкарыла торган территориягә төзүче яки техник заказчы, Инспекция вәкилләрен кертү, аларга тиешле документларны тапшыру, башкарма документларны алып баруны тәэмин итү, төзүчегә яки техник заказчыга, Инспекциягә тикшерүгә тиешле эшләрнең төгәлләнү вакытлары турында хәбәр итү, ачыкланган җитешсезлекләрне юкка чыгаруны тәэмин итү, ачыкланган җитешсезлекләрне юкка чыгару турында актлар төзелгәнчегә кадәр эшләрне дәвам иттерүгә керешүне тыю, кулланыла торган төзелеш материалларының сыйфатына контроль булдыру | РФ ШрК 52 ст. 6 өл. |
| | 22. Кулланыла торган төзелеш материалларының һәм эшләнмәләрнең, шул исәптән төзелеш барган территориядә җитештерелә торган төзелеш материалларының №384-ФЗ Федераль закон, проект документациясе | № 384-ФЗ Федераль законның 34 ст. 1 өл, 3 өл. |

| | | |
|---|---|---|
| | таләпләренә җавап бирүен төзелешнең барлык чорларында контрольдә тоту | |
| Төзүче | 23. Бинаның, төзелмәнең, корылманың, оптималь архитектур, функциональ-технологик, конструктив һәм инженерлык-техник чишелешләрне сайлап алу юлы белән, энергетика нәтиҗәлелеге таләпләренә һәм аларның кулланыла торган энергетика ресурсларын исәпкә алу җайланмалары белән тәэмин ителеш таләпләренә җавап бирүен һәм төзегәндә, үзгәртеп корганда аларның тиешенчә тормышка ашырылуын тәэмин итәргә | № 261-ФЗ Федераль законның 11 ст. 7 өл. |
| Төзүче, техник заказчы | 24. Проект документларын раслау | РФ ШрК 48 ст. 15 өл. |
| | 25. Проект документларын һәм инженерлык эзләнүләре нәтиҗәләрен дәүләт экспертизасына яки дәүләти булмаган экспертизага җибәрү | РФ ШрК 48 ст. 15 өл,<br>РФ ШрК 49 ст. 1 өл. |
| | 26. Җир кишәрлеген, инженерлык эзләнүләре материалларын, проект документларын, төзелешкә рөхсәтне төзү өчен һәм капиталь төзелеш объектын үзгәртеп кору, төзүне башкаручы затка тапшыру өчен әзерләү | ч.4 ст. 52 ГрК РФ |
| | 27. Эшләрне туктату зарурлыгы килеп туганда яки аларны алты айдан артыграк вакытка туктатып тору кирәк булганда капиталь төзелеш объектын консервацияләү | РФ ШрК 52 ст.4 өл. |
| | 28. Капиталь төзелеш объектын төзи, үзгәртеп кора башлаганчыга кадәр җиде эш көненнән соңга калмыйча Инспекциягә мондый эшләрнең башкаруы турында, кирәкле документларны теркәп, хәбәрнамә җибәрү | РФ ШрК 52 ст. 5 өл., Ростехнадзорның 26.12.2006 № 1129 боерыгының 5 п. |
| | 29. Инспекциягә капиталь төзелеш объектын төзүне, үзгәртеп коруны фактта тәмамлаганнан соң төзелешнең тәмамлануы хакында, капиталь төзелеш объектын төзегәндә, үзгәртеп корганда җибәрелгән җитешсезлекләрне юкка чыгару турында, капиталь төзелеш объектын төзүгә, үзгәртеп коруга, шулай | РФ ШрК 54 ст., 5 өл.; Ростехнадзорның 26.12.2006 № 1129 боерыгының 25 п. |

| | | |
|---|---|---|
| | ук төзелеш материалларын (эшләнмәләрне) куллануга бәйле барлык эшләрнең башкарылуына карата башкарма документларның рәсмиләштерелеше турында хәбәрнамә җибәрү | |
| | 30. Төзүне башкаручы затларга тикшерүләрне үткәрү программасында каралган тикшерүләр турындагы белешмәләрне җиткерү | Ростехнадзорның 26.12.2006 № 1129 боерыгының 7 п. |
| | 31. Дәүләт төзелеш күзәтчелеге органындагы вазифаи зат тарафыннан үзенең РФ ШрК 54 статьясында, РФ Хөкүмәтенең № 54 карарының 24 пунктында каралган вәкаләтләрен башкару өчен, шул исәптән төзүче яки техник заказчы белән шартнамә нигезендә төзүне башкаручы затлар аша шартлар тудыруны таләп итәргә. | Ростехнадзорның 26.12.2006 № 1129 боерыгының 10 п. |
| | 32. Тиешле экспертизаларны, тикшеренүләрне, лаборатор һәм башка төрле сынауларны үткәрү өчен, шул исәптән төзүне башкаручы затлар аша, шартлар тудырырга. | Ростехнадзорның 26.12.2006 № 1129 боерыгының 23 п. |

## 4. Тикшерүне үткәргәндә юридик зат, шәхси эшмәкәр тарафыннан тапшырылырга тиешле документлар

Тикшерүнең максатларына ирешү өчен юридик затлар, шәхси эшмәкәрләр тарафыннан тапшырыла торган документларның исемлеге, шулай ук мондый документларның рәвешләрен раслый торган норматив-хокукый актлар 3 таблицада китерелде.

3 таблица – Тикшерүнең максатларына һәм бурычларына ирешү өчен юридик затлар, шәхси эшмәкәрләр тарафыннан тапшырыла торган документларның исемлеге

| Тикшерүне үткәргәндә юридик затлар, шәхси эшмәкәрләр тарафыннан тапшырыла торган документлар | Документның рәвешен билгели торган норматив-хокукый акт |
|---|---|
| 1. Төзүгә рөхсәт | Россия Төзелеш министрлыгының 19.02.2015 №117/пр боерыгы |
| 2. Тулы күләмдә проект документлары, ә төзелешнең, үзгәртеп коруның аерым | - |

| | |
|---|---|
| этапларына рөхсәт бирелгән очракта, тиешле төзелеш этабын башкару өчен кирәкле күләмдә, алар төзүче, техник заказчы тарафыннан расланган булырга тиеш | |
| 3. Проект документларына карата уңай экспертиза бәяләмәсе | - |
| 4. Җирлеккә кызыл линияләрдән чигенеш линияләрен чыгару турындагы документ | - |
| 5. Россия Федерациясе халыкаларының мәдәни мирас объектын (тарихи һәм мәдәни ядкәрләрен) саклау буенча эшчәнлекне башкаруга, шул исәптән, мәдәни мирас объектын саклау буенча эшләр башкарылганда, мондый объектның конструктив һәм башка ышанычлылык һәм куркынычсызлык сыйфатламаларына кагыла торган реставрацияләү эшләрен башкаруга карата лицензия | РФ Хөкүмәтенең “Лицензиянең типик рәвешен раслау турында” 6.10.2011 № 826 карары |
| 6. Капиталь төзелеш объектын төзү, үзгәртеп кору буенча капиталь төзелеш объектының куркынычсызлыгына йогынты ясый торган эш төрләренә кертелү турында таныклыклар | - |
| 7. Эшләрнең гомуми һәм (яки) махсус журналлары | Ростехнадзорның 12.01.2007 № 7 боерыгы |
| 8. Башкарма документлар, шул исәптән: | Ростехнадзорның 26.12.2006 № 1128 боерыгы |
| 8.1 Капиталь төзелеш объектының геодезик бүленмә нигезен таныклау актлары | Ростехнадзорның 26.12.2006 № 1128 боерыгы |
| 8.2. Капиталь төзелеш объектының күчәрләрен бүлү актлары | Ростехнадзорның 26.12.2006 № 1128 боерыгы |
| 8.3. Капиталь төзелеш объектының иминлегенә йогынты ясый торган һәм төзү, үзгәртеп кору технологиясе нигезендә аларны башка эшләрне үткәргәннән соң контрольдә тоту мөмкин булмаган яшерен эшләрне (алга таба – яшерен эшләр) таныклау актлары. Таныкланырга тиешле яшерен эшләрнең исемлеге проект документларында билгеләнә. | Ростехнадзорның 26.12.2006 № 1128 боерыгы |
| 8.4. Алар буенча төзелеш контролен | Ростехнадзорның 26.12.2006 № 1128 |

| | |
|---|---|
| башкарганда ачыкланган җитешсезлекләрне төзелеш конструкцияләрен һәм инженерлык-техник тәэминат челтәрләре өлешләрен эшләмичә яки башкаларына зыян китермичә юкка чыгару мөмкин булмаган җаваплы төзелеш конструкцияләрен (алга таба – җаваплы конструкцияләр) таныклау актлары. Таныкланырга тиешле җаваплы конструкцияләрнең исемлеге проект документларында билгеләнә. | боерыгы |
| 8.5. Алар буенча төзелеш контролен башкарганда ачыкланган җитешсезлекләрне башка төзелеш конструкцияләрен һәм инженерлык-техник тәэминат челтәрләре өлешләрен сүтмичә яки аларга зыян китермичә юкка чыгару мөмкин булмаган инженерлык-техник тәэминат челтәрләре өлешләрен таныклау актлары. Таныкланырга тиешле инженерлык-техник тәэминат челтәрләре өлешләренең исемлеге проект документларында билгеләнә. | Ростехнадзорның 26.12.2006 № 1128 боерыгы |
| 9. Чынлыкта башкарылган эшләрнең төзүне башкаручы затның эш документларына туры килүе турындагы язулар белән берлектә төзүгә, үзгәртеп коруга эш документлары. Төзүне башкаручы зат исеменнән мондый язуларны аталган затның вәкиле вәкиллекне раслый торган документ нигезендә терки. | - |
| 10. Башкарма документлар составына шулай ук түбәндәге материаллар кертелә:<br>- башкарма геодезия схемалары;<br>- башкарма схемалары һәм инженерлык-техник тәэминат челтәрләре өлешләренең профильләре;<br>- техник җайланмаларны сынау һәм кулланып карау актлары;<br>- төзелеш контрое барышында башкарылган эшләргә карата үткәрелгән экспертизаларның, тикшеренүләрнең, лаборатор һәм башка сынауларның нәтиҗәләре; | - |

| | |
|---|---|
| - кулланыла торган төзелеш материалларының (эшләнмәләрнең) сыйфатына контрольлек үткәрелгәнлеген раслый торган документлар;<br>- проект чишелешләрен фактта үтәүне чагылдыра торган башка төрле документлар | |
| 11. Төзелешне оештыру проекты, биналарны һәм корылмаларны, инженерлык һәм транспорт коммуникацияләрен торгызуның эзлеклелеген билгели торган, төзелешнең календарь планында билгеләнгән төзелешнең тәмамлауны вакытлары үтәлешен, әзерлек чорын исәпкә алып (төп һәм ярдәмче биналарны һәм корылмаларны төзү вакытлары һәм эзлеклелеге, төзелеш этапларын бүлү), капиталь төзелеш объектларын яки аларның аерым элементларын күтәргәндә эшләрнең технологик эзлеклелеген тәэмин итә торган, Инспекциядәге вазифаи зат тарафыннан капиталь төзелеш объектына карата тикшерүләрне үткәрү планын эшләү өчен кирәкле булган оештыру-технология схемасы. | - |
| 12. Төзелеш контролен башкарганда һәм дәүләт төзелеш күзәтчелеген гамәлгә ашырганда ачыкланган җитешсезлекләрне юкка чыгару турындагы актлар | - |
| 13. Норматив-хокукый актларда каралган, әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендә Россия Федерациясе законнары таләпләренең, янгын куркынычсызлыгы һәм халыкның санитар-эпидемиологик иминеге таләпләренең, шулай ук энергетика нәтиҗәлелеге таләпләренең һәм капиталь төзелеш объектының кулланыла торган энергетика ресурсларын исәпкә алу җайланмалары белән тәэмин ителү таләпләренең үтәлүен раслый торган документлар | - |
| 14. Административ хокук бозулар турында эшләр буенча карарларның | - |

| | |
|---|---|
| (булган очракта) үтәлешен раслый торган документлар | |
| 15. Техник заказчы вазифаларын (булган очракта) башкаруга, төзелеш контролен (булган очракта) гамәлгә ашыру буенча эшләр башкаруга төзелешне башкару өчен җәлеп ителгән затлар белән, авторлык күзәтчелегенә (булган очракта) шартнамәләр | - |
| 16. Төзелеш контролен башкару өчен җаваплы затны билгеләү турында, эшләрне башкару өчен җаваплы булган затны билгеләү турында, төзүче яки техник заказчы тарафыннан проект документларын раслау турында боерыклар | - |

## 5. Административ процедураларның (гамәлләрнең) составы, эзлеклелеге һәм башкару вакытлары, аларны башкаруга карата таләпләр, шул исәптән административ процедураларны (гамәлләрне) электрон рәвешлә башкару үзенчәлекләре

Административ процедураларның исемлеге

5.1. Дәүләт төзелешен күзәтчелеге түбәндәге административ процедураларны үз эченә ала:

- дәүләт төзелеш күзәтчелеген оештыру һәм аңа әзерләнү
- капиталь төзелеш объектына карата тикшерүне әзерләү һәм үткәрү;
- тикшерү нәтиҗәләрен рәсмиләштерү;
- ачыкланган җитешсезлекләрне юкка чыгару буенча чаралар күрү;
- төзелеше тәмамланган капиталь төзелеш объектын тикшерү.

Дәүләт төзелеш күзәтчелеген башкаруның блох-схемасы әлеге Регламентка карата 2 кушымтада китерелде.

Дәүләт төзелеш күзәтчелеген оештыру һәм аңа әзерләнү

5.2. Шушы Регламентның 2.14 пунктының 1 пунктчасында күрсәтелгән фактның булуы (Инспекциягә төзүчедән, техник заказчыдан теркәлүче документлары белән бергә, эшләрне башлау турында хәбәрнамә (алга таба – эшләр башлану турында хәбәрнамә) килгәндә) административ процедураны башкалу өчен нигез булып тора.

Административ процедура түбәндәге административ гамәлләрне үз эченә ала:

- эшләр башлану турында әмернамәне кабул итү, теркәү, карау;

- дәүләт төзелеш күзәтчелеген башкару турында (башкарудан баш тарту турында) карарлар кабул итү, дәүләт төзелеш күзәтчелеген башкару өчен җаваплы затларны билгеләү;

- вазифаи затларны билгеләү турында боерык әзерләү;

- капиталь төзелеш объектына карата дәүләт төзелеш күзәтчелеген башкару буенча Инспекция эшен (алга таба – күзәтчелек эше) формалаштыру, аңа номер сугу;

- тикшерүләрне үткәрү программасын эшләү.

Эшләр башлану турында хәбәрнамәне кабул итү, теркәү, карау

5.3. Төзүче яки техник заказчы алдан ук, ләкин капиталь төзелеш объектын төзи, үзгәртеп кора башлаганчыга кадәр җиде эш көненнән дә соңга калмыйча, Инспекциягә шушы Регламентның 3 кушымтасына туры китерелгән рәвештә мондый эшләрнең башлануы турында хәбәрнамә җибәрә.

Эшләр башлану турындагы хәбәрнамәгә түбәндәге документлар теркәлә:

1) төзүгә рөхсәт күчермәсе;

2) проект документлары – тулы күләмдә, ә төзүнең, үзгәртеп коруның аерым этабына рөхсәт бирелгән очракта, тиешле төзелеш этабын башкару өчен кирәкле күләмдә;

3) кызыл линияләрдән чыгарылма линияләр җирлеген чыгару турында документ күчермәсе;

4) башкарылган эшләр исәпкә алына торган гомуми һәм махсус журналлар;

5) капиталь төзелеш объектының проект документлары РФ ГрК 49 статьясы нигезендә экспертизага тиешле булса, проект документларының уңай экспертиза бәяләмәсе.

Башкарылган эшләрне исәпкә алу журналлары Инспекциягә брошюраланган рәвештә, номерлар сугылып, титул бите тутырылган хәлдә тапшырыла.

Төзүне башкаручы зат шушы пунктның 1 һәм 5 пунктчаларында күрсәтелгән документларны тапшырмаска хокуклы. Бу очракта Инспекция аталган документларны (аларда булган белешмәләрне) төзүгә рөхсәт биргән органнан мөстәкыйль соратып ала.

5.4. Инспекциядә керә торган корреспонденцияләрне теркәү һәм “Татарстан Республикасы Электрон хөкүмәте” бердәм ведомствоара электрон документ әйләнеше системасында (алга таба – БВЭДӘС администраторы) документ әйләнешен алып бару өчен җаваплы булган зат эшләр башлану турында Инспекциягә килгән хәбәрнамәне терки һәм аны Инспекция башлыгы исеменә җибәрә. Инспекция башлыгының резолюциясе алынганнан соң эшләр башлану турындагы хәбәрнамә, теркәлгән документлары белән бергә, документларны кабул итеп алу өчен җаваплы булган вазифаи затка җибәрелә.

Башкару вакыты: Инспекциягә эшләр башлану турында хәбәрнамә килгән көнне.

Эшнең нәтиҗәсе: БВЭДӘС администраторы тарафыннан теркәлгән, документларны кабул итү өчен җаваплы затка тапшырылган эшләр башлану турында хәбәрнамә.

5.5. Документларны кабул итү өчен җаваплы булган вазифаи зат, теркәлгән документлары белән бергә эшләр башлану турындагы хәбәрнамәне алганнан соң:

1) эшләр башлану турындагы хәбәрнамәнең дөрес тутырылышын тикшерә;

2) тапшырылган документларны аларның составы шушы Ренламентның 5.3 пункты нигезендә тулы булуын, шулай ук аталган документларның эчтәлегенә карата таләпләргә җавап бирүен тикшерә;

3) эшләр башлану турындагы хәбәрнамәдә күрсәтелгән капиталь төзелеш объектын төзегәндә, үзгәртеп корганда дәүләт төзелеш күзәтчелеген башкару кирәклеген тикшерә.

Эшләр башлану турындагы хәбәрнамә Инспекциягә төзүченең (техник заказчының) вәкиле тарафыннан җибәрелгән очракта, эшләр башлану турында хәбәрнамәгә имза салган затның төзүче (техник заказчы) мәнфәгатьләрен яклап гамәл кылу хокукын раслый торган документларның булу-булмавы тикшерелә.

Документларны кабул итеп алу өчен җаваплы булган вазифаи зат документларны тикшергәч түбәндәге гамәлләрне кыла:

зарурлык килеп туган очракта, шушы Регламентның 5.3 пунктының 1 һәм 5 пунктчаларында күрсәтелгән документларны (шушы документлардагы белешмәләрне) төзүгә рөхсәт бирүче органнан сората;

хәбәрнамә белән аңа теркәлә торган документлар билгеләнгән таләпләргә туры килмәгән очракта, аларны, алга таба юкка чыгару өчен, билгеләнгән таләпләргә туры килмәгән өлешләре булу турында теркәлгән аңлатмалары белән бергә, документларны тапшыручы затка кайтарып бирә;

хәбәрнамәдә күрсәтелгән капиталь төзелеш объектын төзегәндә, үзгәртеп корганда дәүләт төзелеш күзәтчелеген гамәлгә ашыру гамәлдәге законнарда каралмаган очракта, баш тарту сәбәпләрен аңлатып, дәүләт вазифасын гамәлгә ашырудан баш тарту турында хат җибәрә;

хәбәрнамә белән аңа теркәлүче документлар билгеләнгән таләпләргә җавап биргән очракта һәм дәүләт вазифасын үтәүдән баш тарту өчен нигезләр булмаганда, эшләр башлану турында килгән хәбәрнамәне дәүләт төзелеш күзәтчелеген башкару өчен җаваплы булган вазифаи затларны билгеләү турында карар кабул итү өчен Инспекция башлыгы урынбасарына җибәрә.

Башкару вакыты: документларны кабул итеп алу өчен җаваплы булган вазифаи зат тарафыннан эшләр башлану турында хәбәрнамә кабул ителгән көннән соң килүче бер эш көне дәвамында.

Эшнең нәтиҗәсе:

- зарурлык булган очракта – документларны сорату;

- ярашмаган өлешләре ачыкланган очракта – хәбәрнамәне тапшырган затка җибәрелгән, эшләр башлану турында хәбәрнамәне кайтарып бирү турында карар;

- гамәлдәге законнарда дәүләт төзелеш күзәтчелеген башкару каралмаган очракта – хәбәрнамәне тапшырган затка җибәрелгән, дәүләт төзелеш күзәтчелеген башкарудан баш тарту турында карар;

- эшләр башлану турындагы хәбәрнамә белән аңа теркәлүче документлар билгеләнгән таләпләргә җавап биргән очракта – теркәлгән документлары белән бергә эшләр башлану турындагы, тикшерелгән, карар кабул итү өчен Инспекция башлыгы урынбасарына җибәрелгән хәбәрнамә.

Дәүләт төзелеш күзәтчелеген башкару (башкарудан баш тарту) турында карар кабул итү, дәүләт төзелеш күзәтчелеген башкару өчен җаваплы затларны билгеләү

5.6. Инспекция башлыгы урынбасары эшләр башлану турында хәбәрнамәне алганнан соң дәүләт төзелеш күзәтчелеген башкару турында карар кабул итә һәм территориаль орган җитәкчесенә (җитәкче урынбасарына) яки территориаль органдагы бүлек башлыгына аны гамәлгә ашыру турында йөкләмә бирә.

Территориаль орган җитәкчесе (җитәкче урынбасары) яки территориаль органдагы бүлек башлыгы дәүләт төзелеш күзәтчелеген башкару өчен җаваплы булган вазифаи затны (вазифаи затларны) билгели, бердән артык вазифаи зат билгеләнгән очракта, алар арасыннан төркем җитәкчесен билгели һәм вазифаи затка (төркем җитәкчесенә) вазифаи затларны билгеләү турында боерык проектын әзерләргә куша.

Башкару вакыты: территориаль орган җитәкчесе (җитәкче урынбасары) яки территориаль органдагы бүлек башлыгы дәүләт төзелеш күзәтчелеген башкару турында йөкләмә кабул иткән көннән соң килүче бер эш көне дәвамында.

Эшнең нәтиҗәсе: дәүләт төзелеш күзәтчелеген башкару (башкарудан баш тарту) турында карар кабул итү, җаваплы буларак билгеләнгән территориаль орган җитәкчесе (җитәкче урынбасары) яки территориаль органдагы бүлек башлыгы, җаваплы башкаручы, төркем җитәкчесе; төркем җитәкчесенә (җаваплы башкаручыга) вазифаи затларны билгеләү турында боерык проектын әзерләргә кушу.

Вазифаи затларны билгеләү турында боерык проектын әзерләү

5.7. Вазифаи зат (төркем җитәкчесе) вазифаи затларны билгеләү турындагы боерык проектын шушы Регламентка карата 4 кушымтага туры китерелгән рәвештә әзерли, аны территориаль органдагы бүлек башлыгы, җитәче (җитәкче урынбасары) белән килештерә һәм имза салу өчен Инспекция башлыгына (башлык урынбасарына) җибәрә.

Вазифаи затларны билгеләү турындагы боерык проекты түбәндәгеләрне күздә тота:

вазифаи затны (вазифаи затларны) билгеләү;

бердән артык вазифаи зат билгеләнгән очракта вазифаи затлар арасыннан төркем җитәкчесен билгеләү;

вазифаи зат (төркем җитәкчесе) тарафыннан тикшерүләрне үткәрү планын (алга таба – тикшерүләр планы) эшләү;

билгеләнгән очракларда тикшерүләр үткәрү;

төзелеш тәмамланган капиталь төзелеш объектына карата тикшерү үткәрү;

вазифаи затларны билгеләү турында боерыкның үтәлешен контрольдә тоту бурычлары.

Вазифаи затны (төркем җитәкчесен) алмаштыру бары тик Инспекция башлыгы (башлык урынбасары) боерыгы нигезендә генә башкарыла.

Вазифаи затларны билгеләү турындагы боерык үтәлешен контрольдә тоту бурычы һәм җаваплылыгы территориаль органның җитәкчесенә (җитәкче урынбасарына), территориаль органдагы бүлек башлыгына йөкләнә.

Башкару вакыты: йөкләмәне кабул иткән көннән соң килүче бер эш көне дәвамында.

Эшнең нәтиҗәсе: вазифаи затларны билгеләү турында карар.

Капиталь төзелеш объектына дәүләт төзелеш күзәтчелеген гамәлгә ашыру буенча күзәтчелек эшен формалаштыру

Тикшерүләрне үткәрү планын эшләү

5.8. Вазифаи зат (төркем җитәкчесе) күзәтчелек эшен Ростехнадзорның 26.12.2006 № 1130 боерыгында билгеләнгән тәртиптә формалаштыра һәм алып бара, аңа номер беркетә. Вазифаи зат (төркем җитәкчесе) күзәтчелек эшен кәгазьдә, шулай ук “ТР Төзелеш күзәтчелеге” электрон мәгълүмат системасында (алга таба – ЭМС) алып бару өчен җаваплы була.

Күзәтчелек эшен формалаштыру һәм алып бару буенча агымдагы контрольне вазифаи затларны билгеләү турында боерык үтәлешен контрольдә тоту җаваплылыгы һәм бурычы йөкләнгән территориаль орган башлыгы (башлык урынбасары), территориаль органдагы бүлек башлыгы гамәлгә ашыра.

5.9. Шушы Регламентның 5.3 пунктында күрсәтелгән эшләр башлану турында хәбәрнамә нигезендә вазифаи зат (төркем җитәкчесе) шушы Регламентның 5 кушымтасына туры китерелгән рәвештә тикшерүләр программасын эшли.

Тикшерүләр программасы капиталь төзелеш объектының конструктив һәм бакша төрле үзенчәлекләрен, капиталь төзелеш объектын яки аның аерым элементларын торгызганда эшләр башкарылуның технологик эзлеклелеген, алга таба эксплуатацияләү шартларын, шулай ук техник регламентлардагы, башка норматив-хокукый актлардагы һәм проект документларындагы таләпләр нигезендә исәпкә алынырга тиешле башка факторларны исәпкә алып эшләнә.

Тикшерүләр программасы вазифаи затларны билгеләү турындагы боерык үтәлеше өчен җаваплы булган зат белән килештерелә һәм Инспекциянең территориаль органы җитәкчесе тарафыннан раслана.

Тикшерүләр программасында түбәндәге белешмәләр күрсәтелә:

а) тикшерүгә тиешле, РФ ШрК 48 статьясының 12 өлешендәге 6 пунктында каралган капиталь төзелеш объектын төзүне оештыру проекты (алга таба – капиталь төзелеш объектын төзүне оештыру проекты) нигезендә билгеләнә торган эшләрнең аталышы;

б) һәр тикшерү предметы;

в) капиталь төзелеш объектын төзүне оештыру проекты нигезендә ачыклана торган, һәр тикшерүне үткәрү буенча якынча датасы;

г) һәр тикшерүне үткәрү өчен дәүләт төзелеш күзәтчелеге органындагы вазифаи затның якынча сарыф ителәчәк вакыты;

д) тикшерүләр программасында каралган, тикшерүләрне үткәргәндә күрсәтелергә тиешле документлар;

е) тикшерүләрне үткәргәндә аларның катнашы тикшерүләр программасында каралган вазифаи затларның яки төзүче, техник заказчы хезмәткәрләренең яки төзүче яки техник заказчы белән ике арадагы шартнамә нигезендә төзүне башкаручы затларның катнашуы зарури булып тора.

Тикшерүләр программасы 2 нөсхәдә төзелә, аның беренчесе Инспекция эшендә кала, икенчесе – төзүчегә яки техника заказчыга (аларның вәкаләтле вәкилләренә) җибәрелә (тапшырыла).

Төзүче яки техника заказчының вәкиле тикшерүләр программасының нөсхәсен кулга алудан (имзалаудан) баш тарткан очракта, документ кулга тапшыру турындагы белдерүнамәсе белән почта аша заказлы хат итеп җибәрелә.

Башкару вакыты: Инспекция (территориаль органнар) тарафыннан эшләр башлану турында хәбәрнамә алынган көннән соң җиде эш көне дәвамында.

Эшнең нәтиҗәсе: эшләнгән һәм төзүчегә яки техник заказчыга тапшырылган (җибәрелгән) тикшерүләр программасы.

5.10. Төзүче, техник заказчы төзүне башкаручы затка тикшерүләр программасында каралган тикшерүләр турындагы белешмәләрне җиткерергә бурычлы.

Төзүче яки техник заказчы алдан ук, ләкин тикшерүләр программасында каралган тикшерүне үткәргәнчегә кадәр җиде эше көненнән дә соңга калмыйча, Инспекциягә тикшерүгә тиешле эшләрнең тикшерүләр программасында күрсәтелгән вакытлары үзгәрү турында хәбәр итәргә бурычлы (әлеге Регламентка карата 6 кушымта).

Шулай ук төзүче яки техник заказчы, алга таба тикшерү үткәрү максатында, Инспекциягә капиталь төзелеш объектын төзегәндә, үзгәртеп корганда барлыкка килгән һәр авария очрагы турында хәбәр итәргә бурычлы (шушы Регламентка карата 7 кушымта).

5.11. Тикшерүләр программасында каралган эшләрне тәмамлау вакытларын үзгәртү турында хәбәрнамә алган очракта вазифаи зат (төркем җитәкчесе), үзгәрешләрне кертү өчен нигезләрне исәпкә алып, билгеләнгән таләпләр нигезендә тикшерүләр программасына үзгәрешләр кертә.

Тикшерүләр программасына кертелгән үзгәрешләр вазифаи затларны билгеләү турында боерык үтәлеше өчен җаваплы булган зат белән килештерелә һәм Инспекциянең территориаль органының җитәкчесе тарафыннан раслана.

Төзүчегә яки техник заказчыга кертелгән үзгәрешләре белән бергә тикшерүләр үткәрү программасын җибәрү (тапшыру) шушы Регламентның 5.9 пунктындагы таләпләрне исәпкә алып башкарыла.

Тикшерүләр программасы нигезендә тикшерүгә тиешле эшләрнең тәмамлану вакытлары үзгәрүе хакында хәбәрнамә булмаганда (үз вакытында тапшырылмаганда) төзүчегә, техник заказчыга, төзүне башкаручы затка карата вазифаи зат (төркем җитәкчесе) РФ КоАП 19.7 статьясы нигезендә чаралар күрә.

Башкару вакыты: Инспекция тарафыннан эшләрне башкаруның чорлары үзгәрү турында хәбәрнамә алынган көннән соң җиде эш көне дәвамында.

Эшнең нәтиҗәсе: тикшерүләр программасына кертелгән үзгәрешләр.

“Дәүләт төзелеш күзәтчелеген оештыру һәм аңа әзерләнү” процедурасы буенча мәгълүмат процедура тәмамланганнан соң 3 эш көне эчендә БТР урнаштырылырга тиешле. БТР сайтына сылтама Инспекциянең рәсми сайтындагы “Дәүләт күзәтчелеге (контроле)” бүлегендә урнашкан.

“Капиталь төзелеш объектына тикшерү үткәрүгә әзерләнү һәм үткәрү” административ процедурасы

5.12. Шушы Регламентның 2.14 пунктында күрсәтелгән фактларның булуы административ процедураны үткәрү нигезе булып тора.

Тикшерүне үткәрү нигезе булып төзүче, техник заказчы яки төзүне башкаручы зат тарафыннан зарури таләпләрне бозу буенча ачыкланган очракларны юкка чыгару турында күрсәтмәне үтәү чорының узуы торса, мондый тикшерүнең предметы булып бары тик Инспекция тарафыннан бирелгән күрсәтмәнең үтәлеше генә тора ала.

Административ процедура түбәндәге административ гамәлләрне үз эченә ала:

- тикшерүне үткәрү турында әмернамә проектын әзерләү;
- тикшереләчәк затка тикшерү үткәреләчәге турында хәбәр итү;
- тикшерүне үткәрү:

документар тикшерү;

урынга чыгып тикшерү.

Тикшерү үткәрү турында әмернамә әзерләү

5.14. Шушы Регламентның 2.14 пунктында күрсәтелгән фактлар булган очракта вазифаи зат (төркем җитәкчесе):

- шушы Регламентка карата 8 кушымтага туры китерелгән рәвештә тикшерү үткәрү турында әмернамә проектын әзерли;
- аны территориаль органдагы бүлек башлыгы, территориаль орган җитәкчесе (җитәкче урынбасары) белән килештерә;
- әмернамә проектын Инспекция башлыгына (башлык урынбасарына) имзалау өчен җибәрә.

Тикшерүдә катнашучы вазифаи затларны алмаштыру, аны үткәрү вакытларын (башлау һәм тәгәлләү даталарын), тикшерүнең предметын яки төрен үзгәртү тикшерүне үткәрү турындагы әмернамәгә үзгәрешләр кертү турындагы әмернамә белән рәсмиләштерелә.

Тикшерүне үткәрү турындагы әмернамәдә өстәмә рәвештә контрольлек буенча тикшерелергә тиешле капиталь төзелеш объектының атылышы һәм урнашкан урыны күрсәтелә.

Шушы Регламентның 2.14 пунктындагы 2 пунктчасында күрсәтелгән фактлар нигезендә тикшерү үткәрелгән очракта вазифаи зат (төркем җитәкчесе), урынга чыгып тикшерү үткәрү турындагы әмернамә проекты белән бергә, төзүченең, техник заказчының яки төзүне башкаручы затның эшчәнлеген гамәлгә ашыру урыны буенча прокуратура органына шушы Регламентның 9 кушымтасына туры китерелгән рәвештә урынга чыгып тикшерү үткәрүне

килештерү турында гариза әзерли, аны бүлек башлыгы, территориаль орган җитәкчесе (җитәкче урынбасары) белән килештерә һәм имзалау өчен Инспекция башлыгына (башлык урынбасарына) җибәрә.

Башкару вакыты: әмернамәне әзерләү һәм имзалау – тикшерүне башлар алдыннан дүрт эш көненнән дә соңга калмыйча;

шушы Регламентның 2.14 пунктындагы 2 пунктчасында күрсәтелгән фактлар нигезендә тикшерү үткәрелгән очракта, – зарурлык булганда кичекмәстән.

Эшнең нәтиҗәсе: тикшерүне үткәрү турында әмернамә; шушы Регламентның 2.14 пунктындагы 2 пунктчасында күрсәтелгән фактлар нигезендә тикшерү үткәрелгән очракта, – тикшерүне үткәрү турында әмернамә һәм прокуратура органнарына урынга чыгып тикшерү үткәрүне килештерү турында гариза.

Тикшереләчәк затка тикшерү үткәрү турында хәбәр итү

5.15. Вазифаи зат (төркем җитәкчесе) төзүчегә, техник заказчыга, төзүне башкаручы затка тикшерү үткәрү турында төзүченең, техник заказчының, төзүне башкаручы затның вәкаләтле вәкиленә (вәкиллек турындагы тиешле документ нигезендә) Инспекция башлыгының (башлык урынбасарының) тикшерү үткәрү турындагы әмернамәсе күчермәсен тапшырып яки кулга тапшыру турындагы белдерүнамә белән почта аша заказлы хат итеп җибәреп, яки башка төрле үтемле ысул белән хәбәр итә.

Башкару вакыты: тикшерүне үткәрүгә кадәр өч эш көненнән дә соңга калмыйча.

Эшнең нәтиҗәсе: төзүчегә, техник заказчыга, төзүне башкаручы затка тикшерү үткәрү турында хәбәр итү.

Төзүчегә, техник заказчыга, төзүне башкаручы затка шушы Регламентның 2.14 пунктындагы 2 пунктчасында күрсәтелгән нигез буенча урынга чыгып тикшерү үткәрү турында алдан ук хәбәр итеп кую таләп ителми.

Үзеннән-үзе җайга салынулы оешманың әгъзаларына карата тикшерү үткәрелгән очракта вазифаи зат (төркем җитәкчесе) аны үткәрер алдыннан өч эш көненнән соңга калмыйча, андагы вәкилнең тикшерүне үткәргәндә катнашу мөмкинлеген яки катнашуын тәэмин итү максатларында, үзеннән-үзе җайга салынулы оешмага белдерүнамә җибәрә (шушы Регламентка карата 10 кушымта).

Тикшерү үткәрү

5.16. Тикшерү документар тикшерү һәм (яки) урынга чыгып тикшерү үткәрү рәвешендә үткәрелә.

Документар тикшерү

5.17. Юридик затның, шәхси эшмәкәрнең аларның оештыру-хокукый рәвешен, хокукларын һәм бурычларын билгели торган, аларның эшчәнлекләрен гамәлгә ашырганда кулланыла торган һәм алар тарафыннан зарури таләпләрнең,

Инспекция күрсәтмәләренең үтәлешенә бәйле документларында булган белешмәләр документар тикшерү предметы булып тора.

5.18. Документар тикшерү Инспекциянең урнашу урыны буенча үткәрелә.

5.19. Документар тикшерү барышында вазифаи затлар иң беренче нәүбәттә төзүче, техник заказчы, төзүне башкаручы зат тарафыннан тапшырылган, Инспекция карамагында булган документларны, күзәтчелек эше материалларын, шул исәптән капиталь төзелеш объектының проект документларын, алдагы тикшерүләрнең актларын, административ хокук бозулар турындагы эшләрне карап тикшерү материалларын һәм төзүчегә, техник заказчыга, төзүне башкаручы затка карата гамәлгә ашырылган дәүләт төзелеш күзәтчелеге нәтиҗәләре турында бүтән документларны карап тикшерә.

Документар тикшерү барышында тапшырылган документларда хаталар һәм (яки) каршылыклар яки әлеге документлардагы белешмәләрнең Инспекциядә булган документлардагы белешмәләргә туры килмәү очраклары ачыкланганда, вазифаи зат, 10 эш көне дәвамында тапшыру таләбе белән, аңлатмалар өчен кирәкле булган дәлилле гарызнамәне язмача рәвештә әзерли һәм билгеләнгән тәртиптә аны төзүчегә, техник заказчыга яки төзүне башкаручы затка җибәрә. Гарызнамәгә мөһер белән таныкланган Инспекция башлыгының, башлык урынбасарының тикшерүне үткәрү турындагы әмернамәсе күчермәсе теркәлә.

Дәлилле гарызнамәне алган көннән башлап ун эш көне эчендә төзүче, техник заказчы яисә төзүне башкаручы зат Инспекциягә гарызнамәдә аталган документларны җибәрергә бурычлы.

Гарызнамәдә күрсәтелгән документлар төзүченең, техник заказчының яки төзүне башкаручы затның, аларның вәкаләтле вәкилләренең мөһере (булган очракта) һәм имзалары белән таныкланган күчермәләре рәвешендә тапшырыла. Төзүче, техник заказчы яисә төзүне башкаручы зат гарызнамәдә аталган документларны Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә, көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документлар рәвешендә җибәрергә хокуклы.

Тапшырылган аңлатмаларны һәм документларны карап тикшергәннән соң яки аңлатмалар булмаган очракта зарури таләпләрнең бозылу билгеләре ачыкланса, вазифаи зат (төркем җитәкчесе), урынга чыгып тикшерү үткәрү турында әмернамә проектын әзерләү юлы белән, урынга чыгып тикшерү үткәрүнең инициаторы булырга хокуклы. Урынга чыгып тикшерү үткәрү турында карарны Инспекция башлыгы, башлык урынбасары кабул итә.

Тикшерүне үткәргәндә Инспекция төзүчедән, техник заказчыдан яки төзүне башкаручы заттан тикшерү предметына кагылмый торган белешмәләрне һәм документларны, шулай ук Инспекция тарафыннан башка органнардан һәм (яки) башка оешмалардан алынырга мөмкин булган белешмәләр белән документларны таләп итәргә хокуклы түгел. Зарурлык килеп туганда, вазифаи затлар шушы Регламентның 1.7 пунктындагы 9 һәм 10 пунктчаларындагы таләпләргә туры китереп билгеләнгән тәртиптә документларны һәм (яки) мәгълүматларны, шул исәптән электрон рәвештә сораталар һәм алалар.

Төзүче, техник заказчы, төзүне башкаручы зат аларны тапшыру законда каралган һәм дәүләт төзелеш күзәтчелеген башкару өчен кирәкле булган белешмәләрне (мәгълүматларны) тапшырмаганда яки үз вакытында

тапшырмаганда, яисә Инспекциягә шундый белешмәләрне (мәгълүматларны) тулы булмаган күләмдә яки ялган рәвештә тапшырганда РФ КоАП каралган тәртиптә, РФ КоАП 19.7 статьясы буенча административ хокук турында эш кузгатыла.

“Документар тикшерү” гамәленең нәтиҗәсе: үткәрелгән контрольлек чаралары.

Башкару вакыты: 20 эш көненнән артык түгел.

Урынга чыгып тикшерү

5.21.Урынга чыгып тикшерү тикшерелә торган капиталь төзелеш объекты урнашкан урында үткәрелә.

5.22. Объектка чыгар алдыннан вазифаи зат, төркем җитәкчесе күзәтчелек эшендәге материаллар, шулай ук объектның проект документлары белән танышып чыгарга бурычлы.

Зарурлык булганда, вазифаи зат шушы Регламентның 1.7 пунктындагы 9 һәм 10 пунктчаларындагы таләпләргә туры китереп билгеләнгән тәртиптә документларны һәм (яки) мәгълүматларны, шул исәптән электрон рәвештә сората һәм ала.

Төзүче, техник заказчы, төзүне башкаручы зат аларны тапшыру законда каралган һәм дәүләт төзелеш күзәтчелеген башкару өчен кирәкле булган белешмәләрне (мәгълүматларны) тапшырмаганда яки үз вакытында тапшырмаганда, яисә Инспекциягә шундый белешмәләрне (мәгълүматларны) тулы булмаган күләмдә яки ялган рәвештә тапшырганда РФ КоАП каралган тәртиптә, РФ КоАП 19.7 статьясы буенча административ хокук турында эш кузгатыла.

5.23. Вазифаи затлар контрольлек объектына килеп җиткәннән соң тикшерүне түбәндәгеләрдән башлый:

- хезмәт таныклыкларын күрсәтеп;

- төзүченең, техник заказчының яки төзүне башкаручы затның җитәкчесен, бүтән вазифаи затын яки вәкаләтле вәкилен тикшерүне үткәрү турындагы әмернамә белән таныштырудан (башлыкның, башлык урынбасарының мөһер белән таныкланган әмернамәсе күчермәсе имзалатып тапшырыла);

- урынга чыгып тикшерү үткәрүче затларның вәкаләтләре белән таныштырып;

- урынга чыгып тикшерүнең максатлары, бурычлары, нигезләре, контрольлек буенча чараларның төрләре һәм күләме, урынга чыгып тикшерүгә җәлеп ителә торган экспертларның, эксперт оешмалары вәкилләренең составы, аны үткәрүнең сроклары һәм шартлары белән таныштырып.

5.24. Төзүченең, техник заказчының яки төзүне башкаручы затның таләбе буенча вазифаи зат Инспекция турында, шулай ук экспертлар, эксперт оешмалары турындагы мәгълүматларны үзенең вәкаләтләрен раслау максатларында күрсәтергә тиеш.

Төзүченең, техник заказчының яки төзүне башкаручы затның җитәкчесе, вазифаи заты яки вәкаләтле вәкиленең таләбе буенча вазифаи зат тикшерелергә

тиешле затларны шушы Регламент һәм капиталь төзелеш объектында контрольлек буенча чараларны үткәрү тәртибе белән таныштырырга тиеш.

5.25. Төзүченең, техник заказчының яки төзүне башкаручы затның җитәкчесен (аның тарафыннан вәкаләт бирелгән затны) тикшерүне үткәрү турында әмернамә белән таныштыру турында тикшерү актында тиешле язу теркәлә.

5.26. Тикшерүне үткәргәндә вазифаи зат шушы Регламентның 3 бүлегендә күрсәтелгән зарури таләпләрнең үтәлешен тикшерә, моның өчен түбәндәге гамәлләрне башкара:

а) төзүче, техник заказчы, төзүне башкаручы зат тарафыннан тикшерүне үткәрү өчен тапшырылган, эшләрне башкаруга (аерым эшләрне, төзелеш конструкцияләрен, инженерлык-техник тәэминат челтәрләре өлешләрен, инженерлык системаларын һәм җайланмаларны да кертеп), төзелеш материалларын (эшләнмәләрен) куллануга, шулай ук төзелеш контрольлеген башкаруга бәйле булган документларны карап тикшерә;

б) башкарылган эшләргә (аерым эшләрне, төзелеш конструкцияләрен, инженерлык-техник тәэминат челтәрләре өлешләрен, инженерлык системаларын һәм җайланмаларны да кертеп), кулланылган төзелеш материалларына (эшләнмәләренә) (алга таба – башкарылган эшләр) визуаль күзәтчелек итә;

в) үткәрелгән тикшерү нәтиҗәләрен рәсмиләштерә;

г) Россия Федерациясенең административ хокук бозулар турындагы законнарында каралган тәртиптә һәм очракларда административ хокук бозуларны кылган затларны административ җаваплылыкка тартуга юнәлдерелгән гамәлләрне кыла.

Шушы пунктның “а”, “б” пунктчаларында каралган гамәлләрнең эзлеклелеге вазифаи зат тарафыннан мөстәкыйль билгеләнә.

5.27. Шушы Регламентның 5.26 пунктындагы “а” пунктчасы нигезендә тикшерүне үткәрү барышында вазифаи зат түбәндәге документларны тикшерә:

- үзеннән-үзе җайга салынулы оешма тарафыннан бирелгән, эшләрне башкаруга кертелү турында таныклның булу-булмавын;

- төзелешне гамәлгә ашыру өчен җәлеп ителгән затлар белән шартнамәләрне;

- башкарылган эшләр исәпкә алына торган гомуми һәм махсус журналларны;

- башкарма документларның, шул исәптән куркынычсызлыкка йогынты ясый торган, аларның башкарылышын контрольдә тоту башка эшләрне башкарганнан соң, шулай ук төзелеш конструкцияләрен һәм инженерлык-техник тәэминат челтәрләре өлешләрен, инженерлык системаларын һәм җайланмаларын сүтмичә яки аларга зыян китермичә мөмкин булмаган эшләрне, төзелеш конструкцияләрен, инженерлык-техник тәэминат челтәрләре өлешләрен, инженерлык системаларын һәм җайланмаларын таныклау актларының булуын һәм дөрес тутырылышын;

- элегрәк үткәрелгән төзелеш контроле барышында һәм дәүләт төзелеш күзәтчелеген гамәлгә ашырганда башкарылган эшләргә карата ачыкланган җитешсезлек очракларын (җитешсезлекләрне) юкка чыгару турындагы актларны;

- төзелеш контроле барышында башкарылган эшләргә карата үткәрелгән экспертизаларның, тикшеренүләрнең, лаборатор һәм башка төрле сынауларның нәтиҗәләрен;

- кулланыла торган төзелеш материалларының сыйфатына карата контрольлек үткәрелгәнлеген раслый торган документларны;

- норматив-хокукый актларда каралган, Россия Федерациясенең әйләнә-тирә мохитне саклау турындагы законнарындагы таләпләрнең, янгын куркынычсызлыгы һәм халыкның санитар-эпидемиологик иминлеге таләпләренең, шулай ук энергетика нәтиҗәлелеге таләпләренең һәм капиталь төзелеш объектының кулланыла торган энергетика ресурсларын исәпкә алу җайланмалары белән тәэмин ителеш таләпләренең үтәлешен раслый торган документларны;

- Инспекция тарафыннан чыгарылган, административ хокук бозулар турында эшләр буенча карарларның үтәлешен раслый торган документларны.

5.28. Вазифаи зат шушы Регламентның 5.26 пунктындагы “б” пунктчасы нигезендә визуаль карау ысулы белән түбәндәгеләрне тикшерә:

- техник регламентлардагы, бүтән хокукый-норматив актлардагы һәм проект документларындагы башкарылган эшләргә карата кулланыла торган таләпләрнең үтәлешен;

- элегрәк үткәрелгән төзелеш контроле барышында һәм дәүләт төзелеш күзәтчелеген гамәлгә ашырганда башкарылган эшләргә карата ачыкланган җитешсезлек очракларын (җитешсезлекләрне) юкка чыгаруны;

- элегрәк үткәрелгән төзелеш контроле барышында һәм дәүләт төзелеш күзәтчелеген гамәлгә ашырганда башкарылган эшләргә карата ачыкланган җитешсезлек очракларын (җитешсезлекләрне) юкка чыгару турындагы актларны төзегәнчегә кадәр эшләр башкаруга керешеп китүгә карата чикләмәнең үтәлешен.

5.29. Проект документларының булмавы яки аның техник регламентлардагы таләпләргә туры килмәгәнлеге ачыкланган очракта башкарылган эшләрне һәм кулланыла торган төзелеш материалларын тикшерү техник регламентларга туры килү-килмәүгә карата башкарыла.

5.30. Тикшерүне үткәргәндә эшләр башлану турында хәбәрнамә тапшырылганчыга кадәр капиталь төзелеш объектын төзи, үзгәртеп кора башлау факты, яисә эшләрне Инспекциягә тикшерүгә тиешле эшләрнең төгәлләнү чорлары үзгәрүе турында хәбәр итмичә торып башкару очрагы ачыкланса, вазифаи зат бинаның конструкцияләренә башкарылган эшләрнең һәм кулланылган төзелеш материалларының техник регламентлардагы һәм проект документларындагы таләпләргә җавап бирүенә карата техник тикшерү үткәрүне таләп итә.

Конструкцияләргә техник тикшерү төзүче, техник заказчы, төзүне башкаручы зат, Инспекциядәге вазифаи зат катнашында үткәрелә. Техник тикшерүнең нәтиҗәләрен чагылдыра торган документның бер нөсхәсе Инспекциянең күзәтчелек эшендә кала.

5.31. Башкарылган эшләргә һәм кулланыла торган төзелеш материалларына (эшләнмәләргә) экспертизалар, тикшеренүләр, лаборатор һәм башка төрле сынаулар үткәрү зарурлыгы килеп туганда Инспекция тарафыннан, Россия Федерауиясе законнары нигезендә, Россия Федерациясе законнарына туры

китереп метрологик тикшерүне (калибровка) яки аттестацияне узган үлчәү чараларыннан файдаланып, контрольлек буенча чаралар үткәрелә (билгеләнә), кирәк булганда Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләнгән тәртиптә аттестацияләнгән экспертлар, Россия Федерациясенең илкүләм аккредитацияләү системасында аккредитацияләү турындагы законнарына туры китереп аккредитацияләнгән эксперт оешмалары җәлеп ителә.

Экспертизалар, тикшеренүләр, лаборатор һәм башка төрле сынаулар башкарыла торган эшләрнең, кулланыла торган төзелеш материалларының техник регламентлардагы, бүтән норматив-хокукый актлардагы һәм проект документларындагы таләпләргә туры килүен раслау максатларында, шулай ук аларны үткәрү проект документларында каралган булсалар һәм (яки) аларны үткәрү Россия Федерациясе законнары һәм бүтән норматив-хокукый актлар нигезендә төзелеш контролен үткәргәндә таләп ителсә, ләкин гамәлгә ашырылмаган очракларда үткәрелә.

5.32. Төзелеш объектларында башкарылган эшләргә һәм кулланыла торган төзелеш материалларына (эшләнмәләргә) экспертизалар, тикшеренүләр, лаборатор һәм/яки башка төрле сынаулар үткәрү белән бергә үткәрелергә тиешле тикшерүләрне оештырганда, Инспекциянең территориаль органнары, тикшерүләр программасы кысаларында, шулай ук гамәлдәге законнарга туры китереп рәсмиләштерелгән хәбәрнамәләр, мөрәҗәгатьләр яки бүтән төрле гарызнамәләр нигезендә, кабул ителгән проект карарын контрольдә тоту чаралары барышында алынган белешмәләрнең объектив, дөрес булуын тәэмин итү һәм ярашлы булуын ачыклау, шулай ук аларның техник регламентлардагы һәм бүтән норматив-хокукый актлардагы таләпләргә туры килүен ачыклау максатында, Инспекциянең экспертизалар үткәрүне күзәтчелек итү буенча территориаль органын җәлеп итә.

Инспекциянең экспертизалар үткәрүне күзәтчелек итү буенча территориаль органындагы махсуслаштырылган бүлекчәне уртак тикшерүләрне үткәрү буенча җәлеп итү өчен вазифаи зат (төркем җитәкчесе) Инспекция тарафыннан билгеләнгән тәртиптә үзенең Инспекциянең территориаль органындагы җитәкчесе исеменә хезмәт язунамәсен җибәрә, анда Инспекциянең экспертизалар үткәрүне күзәтчелек итү буенча территориаль органын җәлеп итү нигезләрен, тикшерүне үткәрү датасын һәм объектның адресын, кирәк булган очракта, мөмкин булган җитешсезлекләрнең һәм бозуларның сыйфаты нигезендә башка төрле сыйфатламаларны күрсәтеп, планлаштырылган инструменталь контрольлек төрләрен күрсәтә.

Алынган хезмәт язунамәсе нигезендә Инспекциянең территориаль органының җитәкчесе, Инспекциянең 08.07.2013 № 67 боерыгы белән расланган Ттерриториаль органнарның Экспертизалар, тикшеренүләр һәм сынаулар үткәрүне күзәтчелек итү буенча территориаль орган белән хезмәттәшлек итү регламентында билгеләнгән тәртиптә, Инспекциянең экспертизалар үткәрүне күзәтчелек итү буенча территориаль органы белгечләрен контроль тикшерүләрне үткәрү өчен җәлеп итә.

Экспертизалар, тикшеренүләр, лаборатор һәм башка төрле сынаулар төзүче, техник заказчы яки төзүне башкаручы зат, Инспекциянең вазифаи заты катнашында үткәрелә.

Төзүче яки техник заказчы тиешле экспертизаларны, тикшеренүләрне, лаборатор һәм башка төрле сынауларны үткәрү өчен, шул исәптән төзүне башкаручы затлар аша, тиешле шартларны тудырырга бурычлы.

5.33. “Урынга чыгып тикшерү” гамәленең нәтиҗәсе: үткәрелгән контрольлек чаралары.

Башкару вакыты: 20 эш көненнән артык түгел.

Үткәрелгән тикшерү (документар, урынга чыгып) буенча мәгълүмат процедура тәмамланганнан соң 3 эш көне эчендә БТР урнаштырылырга тиешле. БТР сайтына сылтама Инспекциянең рәсми сайтындагы “Дәүләт күзәтчелеге (контроле)” бүлегендә урнашкан.

“Тикшерү нәтиҗәләрен рәсмиләштерү” административ процедурасы

“Тикшерү нәтиҗәләрен рәсмиләштерү”

5.34. Тикшерүне тәмамлау административ процедураның нигезе булып тора.

5.35. Тикшерү нәтиҗәләре буенча вазифаи зат (төркем җитәкчесе) билгеләнгән рәвештә (шушы Регламентка карата 11 кушымта) ике нөсхәдә тикшерү актын төзи.

Тикшерү акты, зарури таләпләрнең бозылу очраклары ачыкланганда, төзүчегә, техник заказчыга, төзүне башкаручы затка капиталь төзелеш объектын төзегәндә, үзгәртеп корганда җитешсезлекләрне бетерү турында күрсәтмә (алга таба – күрсәтмә) (шушы Регламентка карата 12 кушымта) бирү нигезе булып тора.

Тикшерү актында түбәндәгеләр күрсәтелә:

1) тикшерү актының датасы, вакыты һәм төзелгән урыны;

2) Инспекциянең аталышы;

3) Инспекция башлыгы (башлык урынбасары) әмернамәсенең датасы һәм номеры;

4) тикшерүне үткәргән вазифаи затның яки вазифаи затларның фамилияләре, исемнәре, аталарының исемнәре һәм вазифалары;

5) тикшерелә торган затның аталышы яки тикшерүне үткәрүдә катнашкан физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме, шулай ук юридик затның җитәкчесенең, бүтән вазифаи затының яки вәкаләтле вәкиленең, шәхси эшмәкәрнең вәкаләтле вәкиленең фамилиясе, исеме, атасының исеме;

6) тикшерүне үткәрү датасы, вакыты, дәвамлылыгы һәм урыны;

7) тикшерү нәтиҗәләре турында, шул исәптән зарури таләпләрнең ачыкланган бозылу очраклары турында, аларның сыйфаты турында һәм аталган бозу очракларына юл куйган затлар турында белешмәләр;

8) тикшерүне үткәргәндә катнашкан юридик затның җитәкчесе, бүтән вазифаи заты яки вәкаләтле вәкиле, шәхси эшмәкәр, аның вәкаләтле вәкиле тикшерү акты белән танышуы яки танышудан баш тартуы турында, аларның имзалары булу яки имза салудан баш тартулары турында белешмәләр, шулай ук тикшерүләрне исәпкә алу журналында үткәрелгән тикшерү турында язу теркәү турында яисә юридик затта, шәхси эшмәкәрдә аталган журналның булмавы сәбәпле мондый язуны теркәү мөмкин булмавы турында белешмәләр;

9) тикшерүне үткәргән вазифаи затның яки вазифаи затларның имзалары.

Тикшерү актында өстәмә рәвештә контрольлек чаралары үткәрелгән капиталь төзелеш объектының аталышы һәм урнашкан урыны күрсәтелә.

Тикшерү актына продукциянең үрнәкләрен сайлап алу беркетмәләре, үткәрелгән тикшеренүләрнең, сынауларның һәм экспертизаарның беркетмәләре яки бәяләмәләре, тикшерелә торган затның зарури таләпләрне үтәү өчен җаваплы булган хезмәткәрләренең аңлатмалары, ачыкланган җитешсезлекләрне юкка чыгару турындагы күрсәтмәләр һәм тикшерү нәтиҗәләренә бәйле булган башка төрле документлар яки аларның күчермәләре, шул исәптән фото, видео, кинотасма материаллары, ачыкланган җитешсезлекләрне теркәп дәлилли торган башка билгеләнгән ысул материллары теркәлә.

Тикшерү актының бер нөсхәсе кушымталарының күчермәләре белән бергә юридик затның җитәкчесенә, бүтән вазифаи затына яки вәкаләтле вәкиленә, шәхси эшмәкәргә, аның вәкаләтле вәкиленә, тикшерү акты белән танышу турында яки танышудан баш тарту турында имзалатып тапшырыла. Тикшерү актының икенче нөсхәсе кушымталарының күчермәләре белән бергә күзәтчелек эшенә урнаштырыла һәм Инспекциядә билгеләнгән тәртиптә саклана.

Юридик затның җитәкчесе, бүтән вазифаи заты яки вәкаләтле вәкиле, шәхси эшмәкәр, аның вәкаләтле вәкиле булмаган очракта, шулай ук тикшерелүче затның тикшерү акты белән танышуы турында язунамә бирүдән яки тикшерү акты белән танышудан баш тартуы очрагында, вазифаи зат (төркем җитәкчесе) тикшерү актын кулга тапшыру турындагы белдерүнамә белән почта аша заказлы хат итеп җибәрә, ул Инспекциядәге күзәтчелек эшендә саклана торган тикшерү акты нөсхәсенә теркәлә.

Тикшерелә торган затның электрон рәвештә хезмәттәшлек итүгә ризалыгы булган очракта тикшерү акты юридик затның җитәкчесенә, бүтән вазифаи затына яки вәкаләтле вәкиленә, шәхси эшмәкәргә, аның вәкаләтле вәкиленә шушы актны төзегән затның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзаланган электрон документ рәвешендә җибәрелергә мөмкин. Шул ук вакытта шушы актны төзегән затның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзаланган электрон документ рәвешендә, аталган документны алуны раcларга мөмкинлек бирә торган ысул белән тикшерелә торган затка җибәрелгән акт тикшерелә торган зат тарафыннан алынган булып санала.

Башкару вакыты: актны рәсмиләштерү һәм тапшыру – тикшерүне үткәргәннән соң турыдан-туры; актны почта аша заказлы хат итеп җибәргән очракта – тикшерүне тәгәлләгәннән соң бер эш көне дәвамында.

Эшнең нәтиҗәсе: тикшерелә торган затка тапшырылган яки тикшерелә торган зат адресына җибәрелгән тикшерү акты.

5.36. Тикшерү актын төзү өчен үткәрелгән тикшеренүләрнең, сынауларның, махсус тикшерүләрнең, экспертизаларның нәтиҗәләре буенча бәяләмә алу кирәк булса, тикшерү акты контрольлек чараларын тәмамлаганнан соң өч эш көненнән артмаган чорда төзелә һәм юридик затның җитәкчесенә, бүтән вазифаи затына яки вәкаләтле вәкиленә, шәхси эшмәкәргә, аның вәкаләтле вәкиленә имзалатып тапшырыла яисә кулга тапшыру турындагы белдерүнамә белән почта аша заказлы хат итеп һәм (яки) шушы актны төзегән затның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзаланган электрон документ рәвешендә (тикшерелә

торган затның дәүләт төзелеш күзәтчелеге кысаларында хезмәттәшлек итүгә ризалыгы булган шарт белән), аталган документның кулга алынуын раслау мөмкинлеге булган ысул белән җибәрелә. Шул ук вакытта аталган документны тапшыру турында белдерүнамә һәм (яки) аны алу турында башка төрле дәлилләмә тикшерү актының Инспекциянең күзәтчелек эшендә саклана торган нөсхәсенә теркәлә.

5.37. Урынга чыгып тикшерү үткәрү өчен аны үткәрүне прокуратура органы белән килештерү таләп ителгән очракта, вазифаи зат (төркем җитәкчесе) тикшерү актының күчермәсен тикшерү үткәрүне килештерү турында карар кабул ителгән прокуратура органына җибәрә.

Башкару вакыты: тикшерү актын төзегән көннән алып биш эш көне дәвамында.

5.38. Юридик зат, шәхси эшмәкәр РФ Икътисадый үсеш министрлыгының 30.04.2009 № 141 боерыгы белән расланган типик рәвештә тикшерүләрне исәпкә алу журналын алып барган очракта, җаваплы башкаручы тикшерүләрне исәпкә алу журналында Инспекциянең аталышы турында, тикшерүне үткәрә башлау һәм тәгәлләү даталары, аны үткәрү вакыты, тикшерүнең хокукый нигезләре, максатлары, бурычлары һәм предметы, ачыкланган җитешсезлекләр һәм бирелгән күрсәтмәләр турындагы мәгълүматларны үз эченә алган язуларны терки, шулай ук тикшерүне үткәргән вазифаи затның яки вазифаи затларның фамилияләре, исемнәре, аталарының исемнәре һәм вазифалары күрсәтелә, имзалары куела.

Тикшерүләрне исәпкә алу журналы тегелгән булырга, номерланырга һәм юридик затның, шәхси эшмәкәрнең мөһере (булган очракта) белән таныкланган булырга тиеш. Тикшерүләрне исәпкә алу журналы булмаган очракта тикшерү актында тиешле язу теркәлә.

Вазифаи зат (төркем җитәкчесе) тикшерү нәтиҗәләре турындагы белешмәләрне эшләрнең гомуми журналына һәм (яки) эшләрнең махсус журналына кертә, аларда башкарылган эшләр исәпкә алынып бара.

Башкару вакыты: тикшерүне тәгәлләгәннән соң турыдан-туры.

Эшнең нәтиҗәсе: үткәрелгән тикшерү турында тикшерүләрне исәпкә алу журналында яки башкарылган эшләрне исәпкә алу журналында тиешле язу.

5.39. Административ процедураны үткәрү нәтиҗәләре:

- кушымталары белән бергә ике нөсхәдә рәсмиләштерелгән тикшерү акты;
- үткәрелгән тикшерү турында тикшерүләрне исәпкә алу журналындагы (булган очракта) һәм (яки) махсус журналлардагы язу;
- тикшерү үткәрүне прокуратура органы белән килештергән очракта – прокуратура органына җибәрелгән тикшерү акты күчермәсе.

Үткәрелгән тикшерү (документар, урынга чыгып) буенча мәгълүмат процедура тәмамланганнан соң 3 эш көне эчендә БТР урнаштырылырга тиешле. БТР сайтына сылтама Инспекциянең рәсми сайтындагы “Дәүләт күзәтчелеге (контроле)” бүлегендә урнашкан.

“Ачыкланган җитешсезлекләрне юкка чыгару буенча чаралар күрү”
административ процедурасы

5.40. Тикшерүне үткәргәндә зарури таләпләрнең бозылу очракларын ачыклау административ процедураны башлау өчен нигез булып тора.

Административ процедура түбәндәге административ гамәлләрне үз эченә ала:

- күрсәтмә һәм (яки) административ хокук бозу турында беркетмә төзү, имзалау;

- зарури таләпләрне бозу очракларын юкка чыгару фактын тикшерү.

Күрсәтмә һәм (яки) административ хокук бозу турында беркетмә төзү

5.41. Тикшерүне үткәргәндә зарури таләпләрне бозу очраклары яисә административ н тикшергәндә РФ КоАП каралган, алар буенча беркетмәләрне Инспекциядәге вазифаи затлар төзергә хокуклы булган административ хокук бозу билгеләре ачыкланган очракта, административ хокук бозулар турында беркетмәләрне төзү өчен вәкаләт бирелгән вазифаи зат, тиешенчә:

а) юридик затка, шәхси эшмәкәргә, аларны юкка чыгару вакытларын күрсәтеп, зарури таләпләрнең бозылу очракларын юкка чыгару турында һәм (яки) кешеләрнең гомеренә, сәламәтлегенә зыян салынуны, хайваннарга, үсемлекләргә, әйләнә-тирә мохиткә, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларына (тарихи һәм мәдәни ядкәрләренә), Россия Федерациясе Музей фонды составына кертелгән музей предметларына һәм музей коллекцияләренә, аеручы кыйммәтле, шул исәптән Россия Федерациясе Архив фондының уникаль, документларына, милли китапханә фонды составына керә торган махсус тарихи, фәнни, мәдәни әһәмияткә ия булган документларга, дәүләт иминлегенә, физик һәм юридик затларның милкәтенә, дәүләти яки муниципаль милеккә зыян китерүне туктату, табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр килеп чыгуны кисәтү чараларын, шулай ук федераль законнарда каралган башка чараларны үткәрү буенча күрсәтмә (шушы Регламентка карата 12 кушымта) әзерли һәм бирә;

б) ачыкланган җитешсезлекләрне юкка чыгаруны контрольдә тоту, аларны кисәтү, мөмкин булган зыян салынуларны булдырмый калу буенча Россия Федерациясе законнары нигезендә чаралар күрә;

в) РФ КоАП каралган административ хокук бозу турында эш кузгата, – шушы Регламентка карата 13 кушымтага туры китерелгән рәвештә административ хокук бозу турында беркетмә төзи һәм аның РФ КоАП билгеләнгән тәртиптә каралуын тәэмин итә.

Башкару вакыты:

күрсәтмәне рәсмиләштерү һәм тапшыру – акт белән бергә, тикшерүне тәмамлаганнан соң турыдан-туры; яисә почта аша заказлы хат итеп җибәрү – тикшерүне тәгәлләгәннән соң бер эш көне дәвамында;

чаралар күрү – ачыкланган җитешсезлекләрне юкка чыгаруның барлык чорында;

административ хокук бозу турында эш кузгату – административ хокук бозуның кылынганлыгын ачыклаганнан соң кичекмәстән.

5.42. Җитешсезлекләр ачыкланган очракта күрсәтмәдә хокук бозу очракларының тасвирламасы, сыйфаты, билгеле бер төре, таләпләре бозылган

норматив-хокукый актларның, техник регламентларның статьяларына (пунктларына, статья өлешләренә), проект документларындагы бүлекләргә (битләргә) сылтамалар күрсәтелә, шулай ук капиталь төзелеш объектының конструтив һәм башка үзенчәлекләрен исәпкә алып, җитешсезлекләрне юкка чыгару вакыты билгеләнә.

Зарурлык булганда, күрсәтмәдә техник регламентлар, нормалар һәм кагыйдәләр нигезендә биналарның һәм корылмаларның техник торышына тикшерү һәм мониторинг үткәрү турында күрсәтмә бирелә.

Тикшерү берничә затка карата үткәрелгән очракта, күрсәтмә һәр тикшерелә торган затка аерым төзелә.

5.43. Үзеннән-үзе җайга салынулы оешма әгъзалары тарафыннан зарури таләпләрнең һәм Россия Федерациясенең шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы законнары бозылу очраклары ачыкланганда, вазифаи зат (төркем җитәкчесе) үзеннән-үзе җайга салынулы оешманың шушы әгъзаларына карата тикшерү үткәргәндә үзеннән-үзе җайга салынулы оешмага ачыкланган хокук бозу очраклары турында тикшерү үткәрүне тәгәлләгән көннән башлап биш эш көне дәвамында хәбәр итә.

5.44. Төзүне башкаручы зат тикшерүне тәэмин итү буенча бурычларын үтәмәгәндә (тиешенчә үтәмәгәндә), вазифаи затның законлы әмеренә буйсынмаганда, административ хокук бозуга сәбәпче булган сәбәпләрне һәм шартларны юкка чыгару буенча чаралар күрмәгәндә, белешмәләрне (мәгълүматларны) тапшырмаганда, РФ КоАП билгеләгән тәртиптә административ хокук бозу турында эш кузгатыла.

5.45. Тикшерүне үткәргәндә төзүне башкаручы затлар, бүтән затлар тарафыннан Россия Федерациясе законнарының бозылу очраклары ачыкланган очракта, аларны ачыклау, юкка чыгару һәм кисәтү мәсьәләләре Инспекция вәкаләтенә карамаса, Инспекция аталган бозулар турында таныклый торган материалларны дәүләт хакимиятенең тиешле вәкаләтле органнарына җибәрергә тиеш.

### Зарури таләпләрне бозу буенча ачыкланган очракларны юкка чыгару фактын тикшерү

5.46. Зарури таләпләрне бозу буенча ачыкланган очракларны юкка чыгару фактын тикшерә башлау нигезләре:

1) зарури таләпләрне бозу буенча ачыкланган очракларны юкка чыгару турында күрсәтмәдә билгеләнгән чорның узуы;

2) зарури таләпләрне бозу буенча ачыкланган очракларны юкка чыгару турында күрсәтмә бирелгән төзүчедән, техник заказчыдан яки төзүне башкаручы заттан (алга таба – күрсәтмә бирелгән зат) хәбәрнамә керү (шушы Регламентка карата 14 кушымта).

5.47. Тикшерү нәтиҗәләре буенча төзелгән зарури таләпләрне бозу буенча ачыкланган очракларны юкка чыгару турында күрсәтмә күрсәтмә бирелгән зат тарафыннан билгеләнгән чорда зарури үтәлергә тиеш.

5.48. Күрсәтмәне биргән вазифаи зат күрсәтмәне үтәү чорларын контрольдә тота.

Зарури таләпләрне бозу буенча ачыкланган очракларны юкка чыгару фактын тикшерү вазифаи зат тарафыннан “Капиталь төзелеш объектын тикшерүгә әзерләнү һәм анны үткәрү” административ процедурасы нигезендә документар яки урынга чыгып тикшерү үткәрү юлы белән башкарыла

Әгәр дә тикшерү барышында зарури таләпләрне бозу буенча элек ачыкланган барлык очракларның да юкка чыгаруы билгеләнсә, тикшерү актында күрсәтмәнең үтәлүе турында тамга куела.

Күрсәтмәнең үтәлмәгәнлеге, шул исәптән тулы күләмдә үтәлмәгәнлеге ачыкланган очракта, тикшерү актында юкка чыгарылмаган барлык җитешсезлекләр күрсәтелә, күрсәтмәне үтәмәү факты буенча административ хокук бозу турында беркетмә төзелә һәм яңа күрсәтмә тапшырыла.

Күрсәтмә бирелгән заттан җитешсезлекләрне юкка чыгару турында хәбәрнамә алыну нигезендә күрсәтмә үтәлешенә карата тикшерү үткәргәндә вазифаи зат тарафыннан җитешсезлекләрне юкка чыгармау факты ачыкланган очракта, аталган затка карата РФ КоАП 19.7 статьясында каралган чаралар күрелә.

Башкару вакыты: шушы Регламентның 5.46 пунктында күрсәтелгән вакыйгалар барлыкка килгән датадан соң 20 эш көненнән артмаган чорда.

Эшнең нәтиҗәсе: күрсәтмәнең үтәлешен тикшерү акты; күрсәтмә үтәлмәгән очракта – күрсәтмәне үтәмәү факты буенча административ хокук бозу турында беркетмә; яңа күрсәтмә.

5.49. Күрсәтмәне үтәү чоры Инспекция тарафыннан күрсәтмә бирелгән затның үтенеч язуы буенча озынайтылырга мөмкин. Үтенеч язуына хокук бозучы тарафыннан хокук бозу очрагын юкка чыгару өчен кирәкле булган чараларның күрелүен раслый торган документлар теркәлә. Шул ук вакытта язмача үтенеч язуы Инпсекциягә күрсәтмәне үтәү чоры тәмамланганчыга кадәр биш эш көненнән дә соңга калмыйча тапшырылырга тиеш.

Үтенеч язуын карау нәтиҗәләре буенча Инспекциянең территориаль органы җитәкчесе тарафыннан түбәндәге карар кабул ителә:

- хокук бозучы тарафыннан үзе булдыра алганча һәм Россия Федерациясе норматив-хокукый актларында каралган, ачыкланган хокук бозу очрагын юкка чыгару өчен кирәкле булган барлык чаралар күрелгән очракта, күрсәтмәне үтәү чорын озынайту турында карар кабул итә – күрсәтмәне үтәү чорын озынайту турында белдерүнамә төзи (шушы Регламентка карата 15 кушымта);

- әгәр дә күрсәтмәдә билгеләнгән чорда хокук бозу очрагын юкка чыгару мөмкин булса, ләкин хокук бозучы тарафыннан аның тарафыннан мөмкин булган, ачыкланган хокук бозу очракларын юкка чыгару өчен кирәкле чаралар күрелмәсә, күрсәтмәне үтәү чорын озынайтудан баш тарту турында карар кабул итә – мондый карарны нигезләп, күрсәтмәне үтәү чорын озынайтудан баш тарту турында язмача хат төзи.

Инспекциянең территориаль органы җитәкчесе имзалаганнан соң белдерүнамә (җавап) күрсәтмә бирелгән затка, аның вәкаләтле вәкиленә тапшырыла яисә мөмкин булган башка төрле ысул белән җибәрелә.

Башкару вакыты: күрсәтмәне үтәү вакытын озынайту турында гозерне үз эченә алган язмача үтенеч язуын теркәгән көннән башлап өч эш көне дәвамында.

Эшнең нәтиҗәсе: күрсәтмә бирелгән затка җибәрелгән, күрсәтмәне үтәү сорын озынайту турында белдерүнамә яисә күрсәтмәне үтәү вакытын озынайтудан баш тарту турында язмача хат.

5.50. Күрсәтмәне үтәү чорын озынайту турында белдерүнамә алгач күрсәтмә бирелгән зат Инспекциягә күрсәтмәнең төп нөсхәсен аңа тиешле язуны теркәү өчен тапшыра.

Күрсәтмәне үтәү чорын озынайту турындагы язу күрсәтмәнең ике нөсхәсендә дә (күрсәтмә бирелгән заттагы нөсхәдә дә һәм Инспекциянең күзәтчелек эшендә саклана торган нөсхәдә дә) теркәлә һәм күрсәтмәне бирүче вазифаи затның имзасы белән таныклана. Аңа язу теркәгәннән соң күрсәтмә нөсхәсен кулга калганда, күрсәтмә бирелгән затның вәкиле аның белән танышып чыгуы турында имза сала.

Күрсәтмәне үтәү чоры тиешле язуны күрсәтмәнең ике нөсхәсенә дә керткән көннән башлап озынайтылган булып санала.

Башкару вакыты: Инспекциягә күрсәтмәнең төп нөсхәсен тапшырган көнне.

Эшнең нәтиҗәсе: күрсәтмәләрнең ике нөсхәсенә дә күрсәтмәне үтәү чорын озынайту турында теркәлгән язу.

Үткәрелгән тикшерү (документар, урынга чыгып) буенча мәгълүмат процедура тәмамланганнан соң 3 эш көне эчендә БТР урнаштырылырга тиешле. БТР сайтына сылтама Инспекциянең рәсми сайтындагы "Дәүләт күзәтчелеге (контроле)" бүлегендә урнашкан.

"Төзелеше тәмамланган капиталь төзелеш объектын тикшерү"
административ процедурасы

5.51. Инспекция тарафыннан төзүчедән, техник заказчыдан капиталь төзелеш объектын төзеп бетерү, үзгәртеп кору турында хәбәрнамә алыну төзелеше тәмамланган объектка карата тикшерү үткәрүнең нигезе булган юридик факт булып тора.

5.52. Объектны фактта төзеп бетергәннән соң, объектны төзү, үзгәртеп кору барышында җибәрелгән барлык җитешсезлекләрне бетергәч, шулай ук объектны төзү буенча барлык эшләрне башкаруга, шулай ук төзелеш материалларын (эшләнмәләрен) куллануга бәйле булган башкарма документларны рәсмиләштергәннән соң, төзүче (техник заказчы) Инспекция башлыгы исеменә капиталь төзелеш объектының төзелеше, үзгәртеп корылышы тәмамлану турында хәбәрнамә җибәрә (шушы Регламентка карата 16 кушымта).

5.53. БВЭДӘС администраторы Инспекция башлыгы исеменә килгән эшләрне төгәлләү турындагы хәбәрнамәне терки һәм, резолюция алынганнан слң, аны тиешле территориаль органга җибәрү.

Бакшару вакыты: Инспекция башлыгының резолюциясе белән бергә эшләрне төгәлләү турында хәбәрнамә алынганнан соң кичекмәстән.

5.54. Эшләр төгәлләнү турында хәбәрнамә алынганнан соң җаваплы башкаручы тикшерүне үткәрү турында әмернамә рәсмиләштерз һәм төзүчегә яки техник заказчыга шушы Регламентның 5.15 пунктына туры китереп, белдерүнамә җибәрә.

Башкару вакыты: тикшерүне билгеләү – Инспекциядә эшләр төгәлләнү турында хәбәрнамәне теркәгәннән соң 7 эш көненнән соңга калмыйча.

Эшнең нәтиҗәсе: төзүчегә яки техник заказчыга җибәрелгән, төзелеше тәмамланган объектка карата тикшерү үткәрү турында белдерүнамә.

5.55. Вазифаи зат төзелеш тәмамланган объектка карата урынга чыгып тикшерүне шушы Регламентның 5.21-5.33 пунктлары нигезендә гамәлгә ашыра, түбәндәгеләрне исәпкә алып:

а) төзелгән, үзгәртеп корылган капиталь төзелеш объекты тулысынча визуаль каралырга тиеш (аерым башкарылган эшләрне, төзелеш конструкцияләрне, инженерлык-техник тәэминат челтәрләре өлешләрен, инженерлык системаларын һәм җайланмаларын һәм кулланылган төзелеш материалларын (эшләнмәләрен) исәпкә алып);

б) дәүләт төзелеш күзәтчелеген башкарганда һәм төзелеш контролен үткәргәндә ачыкланган барлык җитешсезлек очракларын (җитешсезлекләрне) юкка чыгару турындагы барлык актлар (күрсәтмәләр, хәбәрнамәләр) тикшерелергә тиеш.

Башкару вакыты: 20 эш көненнән артык түгел.

Эшнең нәтиҗәсе: төзелеше тәмамланган объектны тикшерү буенча үткәрелгән контрольлек чаралары.

5.56. Җаваплы башкаручы төзелеше тәмамланган объектны тикшерү нәтиҗәләре буенча тикшерү нәтиҗәләрен шушы Регламентның 5.34-5.36, 5.38 пунктларына туры китереп рәсмиләштерә.

Җаваплы башкаручы төзелеше тәмамланган объекты тикшерү актын ике нөсхәдә рәсмиләштерә (бер нөсхә төзүчегә (техник заказчыга) тапшырыла, икенче нөсхәсе Инспекциянең күзәтчелек эшендә кала), ул төзелеше тәмамланган объектка карата тикшерү үткәрүдә катнашучы вазифаи затлар тарафыннан имзалана.

Тикшерүне үткәргәндә зарури таләпләрнең бозылу очраклары ачыкланган очракта, җаваплы башкаручы:

- барлык җитешсезлекләрне тикшерү актында терки;

- шушы Регламентның 5.41-5.45 пунктларында каралган тәртиптә җитешсезлекләрне юкка чыгару турында күрсәтмә төзи һәм төзүчегә яки техник заказчыга тапшыра;

- шушы Регламентның 5.46-5.50 пунктларына туры китереп, зарури таләпләрне бозу буенча ачыкланган очракларны юкка чыгару фактын тикшерә.

Төзелеше тәмамланган объектны тикшерү акты, ачыкланган җитешсезлекләре белән бергә, төзүче яки техник заказчы Ярашлылык турында бәяләмә бирүне сорап мөрәҗәгать иткән очракта, Ярашлылык турында бәяләмәне бирүдән баш тарту турында карар кабул итү өчен нигез булып тора.

5.57. Кисәтүләре булмаган төзелеше тәмамланган объектны тикшерү акты яки төзелеше тәмамланган объектны тикшерү барышында ачыкланган зарури таләпләрне бозу очракларын юкка чыгару турындагы акт төзүче яки техник заказчы өчен Ярашлылык турында бәяләмә бирүне сорап мөрәҗәгать итү өчен нигез булып тора.

Үткәрелгән тикшерү (документар, урынга чыгып) буенча мәгълүмат процедура тәмамланганнан соң 3 эш көне эчендә БТР урнаштырылырга тиешле.

БТР сайтына сылтама Инспекциянең рәсми сайтындагы "Дәүләт күзәтчелеге (контроле)" бүлегендә урнашкан.

Ярашлылык турында бәяләмә яки мондый бәяләмне бирүдән баш тарту турында карарны бирү тәртибе Татарстан Республикасы Дәүләт төзелешен күзәтү инспекциясе боерыгы белән раслана торган Төзелгән, үзгәртеп корылган капиталь төзелеш объектының техник регламентларның һәм проект документларының таләпләренә, шул исәптән энергетика нәтиҗәлелеге таләпләренә һәм капиталь төзелеш объектының кулланыла торган энергия ресурсларын исәпкә алы җайланмалары белән тәэмин ителеше таләпләренә ярашуы турында бәяләмә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты белән җайга салына.

## 6. Дәүләт төзелеш күзәтчелеген тормышка ашыруны контрольдә тоту тәртибе һәм рәвешләре

6.1. Дәүләт төзелеш күзәтчелеген гамәлгә ашыруның тулылыгын һәм сыйфатлы булуын контрольдә тоту агымдагы контрольне, дәүләт вазифасын башкаруны планлы һәм планнан тыш тикшерүләрне, Инспекциядәге, дәүләт вазифасын үтәүдә катнашучы вазифаи затларның карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаятьләрне карап тикшерүне үз эченә ала.

6.2. Шушы Регламентның нигезләмәләре һәм дәүләт вазифасын үтәүгә карата таләпләрне билгели торган бүтән норматив-хокукый актларның үтәлешенә, дәүләт төзелеш күзәтчелеген гамәлгә ашыруның тулылыгына һәм сыйфатлы булуына карата агымдагы контроль Инспекция башлыгы, башлык урындасары, аның территориаль органнары җитәкчеләре, аларның урынбасарлары, территориаль органнарындагы бүлекләрнең башлыклары тарафыннан гамәлгә ашырыла.

6.3. Агымдагы контроль ай саен Инспекциянең вазифаи затлары тарафыннан тапшырыла торган хисапнамәләрне анализлау, шулай ук дәүләт төзелеш күзәтчелеген гамәлгә ашыру барышында Инспекциядәге вазифаи затлар тарафыннан бурычлары үтәлешен тикшерү юлы белән башкарыла.

Инспекциядәге вәкаләтле вазифаи затлар хезмәт вазифаларын тиешенчә үтәмәү очракларын исәпкә алуны оештыра һәм алып бара, тиешле хезмәт тикшеренүләрен үткәрә һәм Россия Федераwиясе законнары нигезендщ мондый вазифаи хатларга карата чаралар күрәләр.

6.4. Тикшерүләр планлы (хисап чорында Инспекциядәге вазифаи затның эш нәтиҗәләре буенча) һәм планнан тыш (дәүләт вазифасын үтәгәндә элек ачыкланган бозуларны юкка чыгаруны тикшерүгә бәйле, Инспекциядәге вәкаләтле вазифаи затның гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаятьне үз эченә алучы мөрәҗәгать нигезендә) булырга мөмкин. Тикшерү барышында дәүләт вазифасын үтәүгә бәйле булган барлык мөәсьәләләр карап тикшерелә.

6.5. Дәүләт төзелеш күзәтчелеген гамәлгә ашыру барышында кабул ителә торган карарлар, башкарыла торган гамәлләр (гамәл кылмаулар) өчен Инспекциядәге вазифаи затлар Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә җаваплы була.

6.6. Әлеге Регламентның таләпләренең үтәлешен гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалары тарафыннан иҗтимагый контрольдә тоту әлеге берләшмәләрнең һәм оешмаларның уставлары, Россия Федерациясе законнары һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә гамәлгә ашырыла. Дәүләт вазифасын үтәү буенча иҗтимагый контрольлекнең Инспекциягә тапшырылган нәтиҗәләре Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә зарури карап тикшерелергә тиешле.

## 7. Дәүләт вазифасын башкаручы органның, шулай ук андагы вазифаи затларның карарларын һәм эшләрен (гамәл кылмауларын) судка кадәр (судтан гайре) шикаять итү тәртибе

7.1. Юридик затлар, шәхси эшмәкәрләр, физик затлар (алга таба – мөрәҗәгать итүчеләр) дәүләт төзелеш күзәтчелеген тормышка ашыру барышында кабул ителгән һәм башкарылган Инспекция һәм аның территориаль органнары, аларның вазифаи затлары карарларына һәм эшләренә (гамәл кылмауларына) карата, югарыда торучы вазифаи затка буйсынучанлык хәлендәге тәртиптә, судка кадәр (судтан гайре) шикаять бирү хокукына ия.

7.2. Мөрәҗәгать итүче кәгазьдә язмача яисә электрон рәвештә шикаять белән мөрәҗәгать итәргә, почта аша тиешенчә яисә Инспекциянең сайты (htpp://gsn.tatarstan.ru) аша Интернетның мәгълүмати-телекоммуникацияләр челтәреннән файдаланып шикаять җибәрергә, шулай ук Инспекциягә һәм аның территориаль органнарына шәхси мөрәҗәгать иткәндә шикаять бирергә хокуклы.

7.3. Инспекциянең һәм аның территориаль органнарының, аларның вазифаи затларының эшләрен (гамәл кылмавын) һәм алар тарафыннан дәүләт вазифасын үтәгәндә кабул ителгән (кабул ителүче) карарларны судка кадәр (судтан гайре) шикаять кылуның предметы булып тора.

7.4. Инспекциягә (территориаль органнарга) яисә вазифаи затка аларның вәкаләтенә ярашлы рәвештә килгән шикаять һичшиксез каралырга тиешле. Судка кадәр (судтан гайре) шикаятьне караудан баш тарту яисә туктату өчен нигезләр каралмаган.

7.5. Шикаять түбәндәгеләрне үз эченә алырга тиеш:

1) дәүләт төзелешен күзәтүне башкаручы территориаль органның исеме һәм (яисә) карарлары, эше (гамәл кылмавы) шикаять ителүче вазифаи затның вазифасы, фамилиясе, исеме, атасының исеме;

2) юридик затның аталышы; шәхси эшмәкәрнең, физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта); урнашкан урыны; әгәр җавап электрон документ формасында җибәрелергә тиеш булса электрон почта адресы, һәм, әгәр җавап язмача формада җибәрелергә тиеш булса – почта адресы.

3) Инспекциянең (территориаль органнарның), андагы вазифаи затларның шикаять ителүче карарлары һәм эшләре (гамәл кылмавы) турындагы белешмәләр;

4) мөрәҗәгать итүче хәбәр итүне тиеш дип санаган башка мәгълүматлар;

5) имза һәм дата.

Шикаятькә шикаятьтә бәян ителгән хәлләрне раслаучы документларның күчермәләре дә беркетелергә мөмкин. Ул очракта шикаятьтә аңа беркетелүче документларның исемлеге күрсәтелә.

7.6. Язмача шикаятьтә аны җибәрүче гражданның фамилиясе (юридик затның аталышы) яки җавап җибәрү мөмкинлеге булган почта адресы (электрон почта адресы) күрсәтелмәсә, шикаятькә җавап бирелми. Әгәр дә аталган шикаятьтә хокукка каршы әзерләнүче, кылына торган яки кылынган гамәлләр турында, шулай ук аны әзерләүче, кылучы яки кылган зат турында белешмәләр булса, шикаять вәкаләте буенча тиешле дәүләт органына җибәрелергә тиеш.

Әгәр дә язмача шикаять текстын укып булмаса, аңа җавап бирелми һәм шикаятьне теркәгән көннән алып җиде көн эчендә шикаятьне юллаган гариза бирүчегә хәбәр ителә, әгәр дә аның фамилиясе (юридик затның аталышы) һәм почта адресы укылышлы булса.

Гариза бирүченең шикаятендә аның тарафыннан моңарчы җибәрелгән шикаятьләргә берничә тапкыр җавап бирелгән сорау каралып, ул сорауның мәгънәсенә карата күп тапкыр язмача җаваплар бирелгән булса, һәм шул ук вакытта шикаятьтә яңа дәлилләр яки шартлар китерелмәсә, башлык (башлык урынбасарлары), вазифаи зат чираттагы шикаятьнең нигезсез булуы турында карар кабул итәргә һәм, әлеге шикаятьнең Инспекциягә юлланган булуы очрагында, гариза бирүче белән әлеге мәсьәлә буенча язышуларны туктатырга хокуклы. Әлеге карар турында шикаятьне юллаган гариза бирүчегә хәбәр ителә;

Әгәр дә шикаятьтә куелган сорауның асылына карата дәүләт яисә федераль закон белән саклана торган башка сер турындагы белешмәләрне таратмыйча җайвап биреп булмаса, шикаятьне юллаган гариза бирүчегә әлеге белешмәләрне тарату мөмкин булмавы сәбәпле куелган сорауның асылына карата җавап биреп булмаганлыгы турында хәбәр ителә.

Эчтәлегендә әдәпсез яисә кимсетүче тәгъбирләр, вазифаи затның гомеренә, сәламәтлегенә һәм мөлкәтенә, шулай ук аның гаилә әгъзаларына янаулар булган шикаятьне алганда Инспекция яки андагы вазифаи зат шикаятьне анда каралган мәсьәләрнең асылы буенча җавап бирмичә калдырырга һәм гариза бирүчегә хокуклар белән килешмәвенең тиешле булмавы хакында хәбәр итәргә хокуклы.

Суд карарына карата шикаять теркәлгән көннән алып җиде көн эчендә, әлеге суд карарын шикаять кылу тәртибе аңлатылып, гариза бирүчегә кире җибәрелә.

Әгәр дә шикаятьтә каралган сорауларның асылына карата җавап бирү мөмкинлеге булмаган сәбәпләр киләчәктә бетерелсә, гариза бирүче шикаятьне Инспекциягә яисә аның вазифаи затына кире юлларга хокуклы.

7.7. Инспекциянең, аның вазифаи затының эшенә (гамәл кылмавына), һәм дәүләт төзелеш күзәтчелеген башкарганда алар тарафыннан кабул ителгән (кабул ителүче) карарларга карата шикаятьнең Инспекциягә керүе шикаятьне судка кадәр (судтан гайре) карау процедурасын башлау өчен нигез булып тора.

7.8. Юридик затлар, шәхси эшмәкәрләр, физик затлар шикаятьне карау өчен һәм нигезләү өчен кирәкле мәгълүматларны һәм документларны алуга хокуклы. Мондый төрдәге мәгълүматны һәм документларны алу өчен юридик затлар, шәхси эшмәкәрләр, физик затлар Инспекция адресына язмача яисә электрон формада тиешле сорауны юлларга тиеш. Инспекциянең вазифаи затлары юридик

затка, шәхси эшмәкәргә, физик затка гарызнамәне теркәгән көннән башлап 30 календарь көне дәвамында турыдан-туры аның хокукларына һәм ирегенә кагылышлы документлар һәм материаллар белән танышу мөмкинлеген бирергә тиеш, әгәр дә мәгълүматка карата Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән чикләүләр каралмаган булса.

7.9. Инспекциядәге вазифаи затларның эшенә (гамәл кылмавына) карата шикаять Инспекция башлыгына (башлык урынбасарына) юлланырга мөмкин.

Инспекциянең, Инспекция башлыгының карарларына, эшенә (гамәл кылмавына) шикаять Татарстан Республикасының Министрлар Кабинетына юлланырга мөмкин.

7.10. Шикаять Инспекция тарафыннан аның теркәлү көненнән алып утыз календарь көне эчендә карала.

7.11. Шикаятьне судка кадәр (судтан гайре) карауның нәтиҗәләре булып түбәндәгеләр тора:

дәүләт төзелеш күзәтчелеген башкарганда кабул ителгән (кабул ителүче) карарларга һәм эшләргә карата шикаятьне судка кадәр (судтан гайре) карауны канәгатьләндерү;

дәүләт төзелеш күзәтчелеген башкаргандагы гамәлләргә (гамәл кылмауга) һәм кабул ителгән (гамәлгә ашырыла торган) карарларга судка кадәр (судтан гайре) шикаять кылуны канәгатьләндермәү.

Шикаятьне карап тикшерү турында дәлилләнгән җавап мөрәҗәгать итүчегә язмача рәвештә яки аның ихтыяры буенча электрон рәвештә шушы Административ регламентның 7.10 пунктында күрсәтелгән вакыт кысаларында җибәрелә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт төзелешен күзәтү инспекциясе
тарафыннан Татарстан Республикасында
төбәк дәүләт төзелеш күзәтчелеге буенча
дәүләт вазифасын башкаруның
административ регламентына
1 кушымта

Татарстан Республикасы Дәүләт төзелешен күзәтү
инспекциясендә административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзү
вәкаләте бирелгән вазифаи затлар
ИСЕМЛЕГЕ*

1. Татарстан Республикасы Дәүләт төзелешен күзәтү инспекциясе башлыгы;

2. Татарстан Республикасы Дәүләт төзелешен күзәтү инспекциясе башлыгының беренче урынбасары;

3. Инспекциядәге территориаль органнарның җитәкчеләре һәм җитәкчеләрнең урынбасарлары;

4. Инспекциянең территориаль органнарындагы бүлекләрнең башлыклары;

5. Консультантлар, әйдәп баручы белгечләр – экспертлар, 2 разрядлы өлкән белгечләр, өлкән белгечләр, 1 категория белгечләре.

* Исемлектә күрсәтелгән Татарстан Республикасы Дәүләт төзелешен күзәтү инспекциясендәге вазифаи затлар Россия Федерациясенең Административ хокук бозулар турында кодексының 28.3 статьясы, асылда Россия Федерациясенең Административ хокук бозулар турында кодексының 6.3, 8.1, 9.4, 9.5, 9.5.1 статьялары (капиталь төзелеш объектын төзүче, үзгәртеп коручы затлар тарафыннан кылынган административ хокук бозулар өлешендә), 9.16 статьясының 3 өлеше, 14.44 статьясы, 19.4 статьясының 1 өлеше, 19.5 статьясының 6 һәм 15 өлешләре, 19.6, 19.7 һәм 19.33 статьялары, 20.4 статьясының 1-6.1, 8 өлешләре, 20.25 статьясының 1 өлеше нигезендә административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә хокуклы.

Татарстан Республикасы
Дәүләт төзелешен күзәтү инспекциясе
тарафыннан Татарстан Республикасында
төбәк дәүләт төзелеш күзәтчелеге буенча
дәүләт вазифасын башкаруның
административ регламентына
2 кушымта

# Татарстан Республикасы Дәүләт төзелешен күзәтү инспекциясе тарафыннан Татарстан Республикасында төбәк дәүләт төзелеш күзәтчелеге буенча дәүләт вазифасын башкаруның блок-схемасы

Эшләр башлану турында хәбәрнамәне кабул итү, теркәү, карау
(эшләр башлану турында хәбәрнамә алынганнан соң бер эш көнендә)

Дәүләт төзелеш күзәтчелеген башкару өчен җаваплы затлар билгеләү
(алдагы процедура тәмамланганч бер эш көне дәвамында)

Вазифаи затларны билгеләү турында боерык әзерләү
( алдагы процедура тәмамланганч бер эш көне дәвамында)

Күзәтчелек эшен формалаштыру һәм тикшерүләр программасын эшләү
(Инспекция (территориаль органнар) тарафыннан эшләр башлану
турында хәбәрнамә алынгач җиде эш көне дәвамында)

Тикшерүләр үткәрүгә әзерлек

Тикшерү үткәрү турында әмернамә
әзерләү
(тикшерү башланырга дүрт эш
көненнән соңга калмыйча)

Тикшереләчәк затка тикшерү үткәреләчәге турында хәбәр итү
(үткәреләчәк тикшерүгә кадәр өч эш көненнән соңга калмыйча)

ҮЖО әгъзасын тикшергән очракта, ҮЖОга тикшерү үткәрү
турында хәбәрнамә җибәрү (үткәреләчәк тикшерүгә кадәр өч эш
көненнән соңга калмыйча)

Согласование (при необходимости) выездной проверки с
органом прокуратуры (в течение одного рабочего дня, со дня
окончания предыдущей процедуры)

Тикшерү үткәрү

**Документарная проверка**

Инспекция карамагында булган документларны вазифаи зат тарафыннан карау;
Зарурлык булганда, тикшерелә торган зат адресына тапшырылган документларның билгеләнгән таләпләргә туры килмәве турында хат (дәлилле гарызнамә) җибәрү;
гарызнамәгә тикшерүне үткәрү турындагы әмернамәнең күчермәсе теркәлә;
Вазифаи затның тапшырылган документларны өйрәнүе (20 эш көненнән артык түгел)

**Выездная проверка**

Вазифаи затның күзәтчелек эшендәге материаллар, проект документлары белән танышуы;
Объектка килгәч – хезмәт таныклыгын күрсәтү, тикшерелә торган затның вәкилен тикшерү үткәрү турындагы әмернамә, урынга чыгып тикшерүнең максатлары, бурычлары, нигезләре, контрольлек чараларының төрләре һәм күләме, тикшерү үткәрүнең сроклары һәм шартлары белән таныштыру (20 эш көненнән артык түгел)


При необходимости, принятие решения о проведении выездной проверки
Проведение выездной проверки согласно распоряжению
Тикшерү нәтиҗәләрен рәсмиләштерү
(тикшерү актын рәсмиләштерү, үткәрелгән тикшерү турында тикшерүләрне исәпкә алу журналына, гомуми һәм (яки) махсус журналларга язу теркәү, бердәм тикшерүләр реестрына тиешле мәгълүмат кертү)
Тикшерелә торган затның вәкилен тикшерү акты (ачыкланган җитешсезлекләрне юкка чыгару турында күрсәтмә) белән таныштыру
(тикшерү тәмамлангач турыдан-туры)
Тикшерү актының күчермәләрен прокуратура органына җибәрү (прокуратура органы белән килештергәндә) (тикшерү беткәч биш эш көне дәвамында)
Төзелеше тәмамланган капиталь төзелеш объектын тикшерү (20 эш көненнән артык түгел)
Ярашлылык турында бәяләмә бирү яки Ярашлылык турында бәяләмә бирүдән баш тарту турында карар
Зарури таләпләрне бозулар ачыкланганда
Ачыкланган бозуларны юкка чыгару буенча чаралар күрү
Зарури таләпләрне бозу очракларын юкка чыгару турында күрсәтмә төзү, ул тикшерү актына теркәлә
Административ хокук бозу турында беркетмә төзү, аның РФ КоАП билгеләгән тәртиптә каралуын тәэмин итү
ҮҖО әгъзасы тарафыннан бозулар ачыкланганда: ачыкланган бозулар турындагы белешмәләрне ҮҖОга җибәрү
Зарури таләпләрне бозу очракларын юкка чыгару буенча тикшерү үткәрү (шушы Регламентның 5.46 пунктында күрсәтелгән вакыйгалар булган датадан соң 20 эш көненнән артык түгел)

Татарстан Республикасы
Дәүләт төзелешен күзәтү инспекциясе
тарафыннан Татарстан Республикасында
төбәк дәүләт төзелеш күзәтчелеге буенча
дәүләт вазифасын башкаруның
административ регламентына
3 кушымта

(Үрнәк рәвеше)

Эшнең номеры_____________ ___________нөсхә

КАПИТАЛЬ ТӨЗЕЛЕШ ОБЪЕКТЫН ТӨЗИ, ҮЗГӘРТЕП КОРА
БАШЛАУ ТУРЫНДА №_________ ХӘБӘРНАМӘ

________________________ «__»____________ 20__ ел.
(төзү урыны)

1. Төзүче, техник заказчикчы____________________________________________________________
(төзүченең, техник заказчының аталышы
___________________________________________________________________________
(техник заказчы булганда), дәүләт теркәве турында таныклыкның номеры һәм бирелү датасы,
___________________________________________________________________________
ОГРН, ИНН, почта реквизитлары, телефон/факс – юридик затлар өчен;
___________________________________________________________________________
төзүченең яки техник заказчының фамилиясе, исеме, атасының исеме,
___________________________________________________________________________
паспорт белешмәләре, яшәгән урыны, телефон/факс – физик затлар өчен)

2. Капиталь төзелеш объекты_____________________________________________________________
(капиталь төзелеш объектының аталышы, сыйфатламалары,
___________________________________________________________________________
төзелешнең, үзгәртеп коруның этапларын, мондый объектның конструктив һәм ышанычлылык һәм куркынычсызлык сыйфатламаларына кагыла торган мәдәни мирас объектын саклау буенча эшләрне тасвирлау,
___________________________________________________________________________
әгәр дә рөхсәт этапка бирелгән булса)

3. Капиталь төзелеш объектының адресы (урнашу урыны) _________________________________
(капиталь төзелеш объектының
___________________________________________________________________________
почта яки төзелеш адресы)

4. Капиталь төзелеш объектын төзүгә рөхсәт_____________________________________________
(номеры һәм
___________________________________________________________________________
бирелү датасы, кем тарафыннан бирелгән, гамәлдә булу вакыты)

5. Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 49 статьясы нигезендә проект документларына карата уңай экспертиза бәяләмәсе (типик проект документларыннан яки аның типик проект документлары реестрына кертелгән модификациясеннән файдаланганлыкны күрсәтергә)_______________________________________________________________
(номеры һәм бирелү датасы, кем тарафыннан бирелгән)
___________________________________________________________________________

6. Проект документларына карата уңай дәүләт экология экспертизасы бәяләмәсе, әгәр дә капиталь төзелеш объектының проект документлары дәүләт экология экспертизасына тиешле булса________________________________________________________________________________

(номеры һәм бирелү датасы, кем тарафыннан бирелгән)

________________________________________________________________________________

7. Мәдәни мирас объектын саклау буенча мондый объектның конструктив һәм ышанычлылык һәм куркынычсызлык буенча башка сыйфатламаларына кагыла торган төзелешне, үзгәртеп коруны, эшләрне башлау________________________________________________________________

(эшләрне башлау датасы)

8. Мәдәни мирас объектын саклау буенча мондый объектның конструктив һәм ышанычлылык һәм куркынычсызлык буенча башка сыйфатламаларына кагыла торган төзелешне, үзгәртеп коруны, эшләрне тәмамлау______________________________________________________________

(эшләрне төгәлләү датасы)

9. Реквизитларын һәм капиталь төзелеш объектының куркынычсызлыгына йогынты ясый торган билгеле бер эш төренә яки төрләренә кертелү турындагы таныклыкларны күрсәтеп, төзүче яки техник заказчы белән шартнамә нигезендә җәлеп ителә торган шәхси эшмәкәрләрнең яки төзүне башкаручы юридик затларның исемлеге һәм алар әгъза булып торучы үзеннән-үзе җайга салынулы оешмаларның аталышлары

________________________________________________________________________________

________________________________________________________________________________

________________________________________________________________________________

10. Әлеге хәбәрнамәгә теркәлә:________________________________________________

(Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 52 статьясының

________________________________________________________________________________

5 өлеше нигезендә хәбәрнамәгә теркәлә торган документлар)

________________________________________________________________________________

________________________________________________________________________________

Хәбәрнамәдә күрсәтелгән мәгълүматларның дөреслеген раслыйбыз.

Шушы хәбәрнамәдә китерелгән белешмәләргә бәйле барлык үзгәрешләр хакында үзгәрешләр барлыкка килгән чордан башлап өч көн эчендә Инспекциягә хәбәр итү бурычын үз өстебезгә алабыз.

______________________________ ________________ __________________________

(вазифаи) (имза) (имзаның аңлатмасы)

М.У.

(юридик зат булган төзүче

яки техник заказчы өчен)

Алу турында тамга:

*(дәүләт төзелеш күзәтчелеге органы вазифаи заты тарафыннан тутырыла)*

«____» __________ _____ел.

Татарстан Республикасы
Дәүләт төзелешен күзәтү инспекциясе
тарафыннан Татарстан Республикасында
төбәк дәүләт төзелеш күзәтчелеге буенча
дәүләт вазифасын башкаруның
административ регламентына
4 кушымта

(Үрнәк рәвеше)

________________________________________________
(дәүләт төзелеш күзәтчелеге органының аталышы һәм дәүләт төзелеш күзәтчелеге органының боерыкларын (әмернамәләрен) рәсмиләштерүгә карата таләпләр нигезендә башка реквизитлар)

**БОЕРЫК**

«____»____________201_ ел.                                   №__________________

________________________
(төзү урыны)

Вазифаи затны
билгеләү турында

____________________________________________________адресы буенча урнашкан
(капиталь төзелеш объектының почта яки төзелеш адресын күрсәтергә)
_______________________________________________________________мәдәни мирас
(объектның аталышы)
объектын саклау буенча мондый объектның конструктив һәм ышанычлылык һәм куркынычсызлык буенча башка сыйфатламаларына кагыла торган төзелешне, үзгәртеп коруны гамәлгә ашыруга, эшләр башкарылуга төбәк дәүләт төзелеш күзәтчелеген башкару максатларында (кирәклесен сайларга)

БОЕРЫК БИРӘМ:

1. Түбәндәге белгечләрне мәдәни мирас объектын саклау буенча мондый объектның конструктив һәм ышанычлылык һәм куркынычсызлык буенча башка сыйфатламаларына кагыла торган төзелешне, үзгәртеп коруны гамәлгә ашыруга, эшләр башкарылуга (кирәклесен сайларга) төбәк дәүләт төзелеш күзәтчелеген башкару өчен җаваплы, вәкаләтле булган вазифаи затлар итеп билгеләргә:

________________________________________________________________
(вазифасы, Ф.И.А., күзәтчелек төре)

2. ____________________________________________________________
(вазифасы, Ф.И.А.)
мәдәни мирас объектын саклау буенча мондый объектның конструктив һәм ышанычлылык һәм куркынычсызлык буенча башка сыйфатламаларына кагыла торган төзелешне, үзгәртеп коруны гамәлгә ашыруганда, эшләр башкарганда (кирәклесен сайларга) тикшерүләр үткәрү программасын эшләргә.

3. Билгеләнгән вазифаи затлар тикшерүләрне үзләренең вазифаи регламентлары (күрсәтмәләре) белән башкаралар, түбәндәге очракларда:

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 52 статьясының 5 һәм 6 статьялары нигезендә капиталь төзелеш объектын саклау буенча мондый объектның конструктив һәм ышанычлылык һәм куркынычсызлык буенча башка сыйфатламаларына кагыла торган төзелешне, үзгәртеп коруны, эшләрне башлау турында, шулай ук җитешсезлекләрне юкка чыгару турында, капиталь төзелеш объектын төзеп бетерү, үзгәртеп коруны тәмалау, мәдәни

мирас объектын саклау буенча мондый объектның конструктив һәм ышанычлылык һәм куркынычсызлык буенча башка сыйфатламаларына кагыла торган эшләрне тәгәлләү турында төзүчедән, техник заказчыдан яки төзүне башкаручы заттан хәбәрнамә алынганда;

тикшерүләр программасы нигезендә;

төзүчедән, техник заказчыдан яки төзүне башкаручы заттан тикшерүгә тиешле эшләрне тәмамлау чорлары үзгәрү турында хәбәрнамә алынганда, әгәр дә мондый эшләрне тәгәлләү вакытлары тикшерүләрне үткәрү программасында күрсәтелгән вакытларга туры килмәсә;

төзүне башкаручы заттан капиталь төзелеш объектында аварияле очраклар барлыкка килү турында хәбәрнамә алынганда;

юридик зат, шәхси эшмәкәр тарафыннан дәүләт төзелеш күзәтчелеге органы биргән ачыкланган зарури таләпләрне бозу очракларын юкка чыгару турында күрсәтмәне үтәү вакыты узганда;

дәүләт төзелеш күзәтчелеге органы җитәкчесенең (җитәкче урынбасарының) тикшерүне үткәрү турында Россия Федерациясе Президенты яки Россия Федерациясе Хөкүмәте йөкләмәсе нигезендә яисә прокурорның прокуратура органнарына килгән материаллар һәм мөрәҗәгатьләр буенча күзәтчелек итү кысаларында планнан тыш тикшерү үткәрү турындагы таләбе нигезендә чыгарылган боерыгы булу;

капиталь төзелеш объектын төзегәндә, үзгәртеп корганда барлыкка килгән аварияләр, техник регламентларны, башка норматив-хокукый актларны һәм проект документларын бозу очраклары, шул исәптән кулланыла торган төзелеш материалларына карата белдерелә торган зарури таләпләрнең бозылу очраклары турында гражданнардан, шул исәптән шәхси эшмәкәрләрдән, юридик затлардан мөрәҗәгатьләр һәм гаризалар, дәүләт хакимияте органнарыннан (дәүләт күзәтчелеге органы вазифаи затларыннан), җирле үзидарә ораганнарыннан, массакүләм мәгълүмат чараларыннан алынган мәгълүматлар, әгәр дә мондый бозулар кешеләрнең гомеренә, сәламәтлегенә, әйләнә-тирә мохиткә, дәүләт иминлегенә, физик затларның һәм юридик затларның мөлкәтенә, дәүләти яки муниципаль милеккә зыян салыну куркынычын тудырса яисә шундый зыян салынуга китергән булса;

4. Төзүчедән яки техник заказчыдан капиталь төзелеш объектын төзеп бетерү, үзгәртеп коруны тәмамлау, мәдәни мирас объектын саклау буенча мондый объектның конструктив һәм ышанычлылык һәм куркынычсызлык буенча башка сыйфатламаларына кагыла торган эшләрне тәгәлләү (кирәклесен сайларга) турында хәбәрнамә алынганнан соң төзелеш тәмамланган капиталь төзелеш объектына карата тикшерү үткәрергә һәм капиталь төзелеш объектын төзегәндә, үзгәртеп корганда башкарылган эшләрнең һәм кулланыла торган төзелеш материалларының, шулай ук мондый эшләрнең нәтиҗәләренең техник регламентлардагы, проект документларындагы таләпләргә, шул исәптән энергетика нәтиҗәлелеге таләпләренә һәм капиталь төзелеш объектының кулланыла торган энергетика ресурсларын исәпкә алу җайланмалары белән тәэмин ителеш таләпләренә ярашуы турында бәяләмә яки мондый бәяләмәне бирүдән баш тарту турында карар әзерләргә.

5. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча____________________________________
____________________________________________________________җаваплы итеп билгеләргә.

(вазифасы, Ф.И.А.)

____________________________ ______________ _________________________

(вазифа) (имза) (имзаның аңлатмасы)

Искәрмәләр.

1. Һәр капиталь төзелеш объектын төзегәндә, үзгәртеп корганда дәүләт төзелеш күзәтчелеген гамәлгә ашыру өчен таләп ителә торган вазифаи затларның күләме Инспекция башлыгы (башлык урынбасары) тарафыннан билгеләнә. Капиталь төзелеш объектын төзегәндә, үзгәртеп корганда дәүләт төзелеш күзәтчелеген гамәлгә ашыру өчен бердән артык вазифаи затны билгеләгәндә алар арасыннан җаваплы зат (төркем җитәкчесе) билгеләнә.

2. Капиталь төзелеш объектын төзегәндә, үзгәртеп корганда дәүләт төзелеш күзәтчелеген гамәлгә ашыру өчен бердән артык вазифаи зат билгеләнгән очракта тикшерүләр программасы мондый затлар белән бергә эшләнә.

3. Боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча вазифаларны боерыкны чыгарган зат ихтыярына йөклим.

Татарстан Республикасы
Дәүләт төзелешен күзәтү инспекциясе
тарафыннан Татарстан Республикасында
төбәк дәүләт төзелеш күзәтчелеге буенча
дәүләт вазифасын башкаруның
административ регламентына
5 кушымта

(Үрнәк рәвеше)

ТИКШЕРҮЛӘРНЕ ҮТКӘРҮ ПРОГРАММАСЫ

Эш номеры______________ ___________нөсхә

РАСЛЫЙМ

_________________________________________
(Инспекциянең территориаль органы җитәкчесе яки
аның вазифаларын башкаручы зат)

______________________________
(имза) (имзаның аңлатмасы)
«____»_______________________ 20__ ел.

1. Төзүче, техник заказчикчы_______________________________________________________________
(төзүченең, техник заказчының аталышы

_____________________________________________________________________________________
(техник заказчы булганда), дәүләт теркәве турында таныклыкның номеры һәм бирелү датасы,

_____________________________________________________________________________________
ОГРН, ИНН, почта реквизитлары, телефон/факс – юридик затлар өчен;

_____________________________________________________________________________________
төзүченең яки техник заказчының фамилиясе, исеме, атасының исеме,

_____________________________________________________________________________________
паспорт белешмәләре, яшәгән урыны, телефон/факс – физик затлар өчен)

2. Капиталь төзелеш объекты_____________________________________________________________
(капиталь төзелеш объектының аталышы, сыйфатламалары,

_____________________________________________________________________________________
төзелешнең, үзгәртеп коруның этапларын, мондый объектның конструктив һәм ышанычлылык һәм куркынычсызлык сыйфатламаларына кагыла торган мәдәни мирас объектын саклау буенча эшләрне тасвирлау,

_____________________________________________________________________________________
әгәр дә рөхсәт этапка бирелгән булса)

3. Капиталь төзелеш объектының адресы (урнашу урыны) _______________________________
(капиталь төзелеш объектының

_____________________________________________________________________________________
почта яки төзелеш адресы)

4. Капиталь төзелеш объектын төзүгә рөхсәт_____________________________________________
(номеры һәм

_____________________________________________________________________________________
бирелү датасы, кем тарафыннан бирелгән, гамәлдә булу вакыты)

5. Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 49 статьясы нигезендә проект документларына карата уңай экспертиза бәяләмәсе (типик проект документларыннан яки аның типик проект документлары реестрына кертелгән модификациясеннән файдаланганлыкны күрсәтергә)_____________________________________________________________________
(номеры һәм бирелү датасы, кем тарафыннан бирелгән)

_____________________________________________________________________________________

6. Проект документларына карата уңай дәүләт экология экспертизасы бәяләмәсе, әгәр дә капиталь төзелеш объектының проект документлары дәүләт экология экспертизасына тиешле булса_______________________________________________________________________________

(номеры һәм бирелү датасы, кем тарафыннан бирелгән)

_______________________________________________________________________________

7. Мәдәни мирас объектын саклау буенча мондый объектның конструктив һәм ышанычлылык һәм куркынычсызлык буенча башка сыйфатламаларына кагыла торган төзелешне, үзгәртеп коруны, эшләрне башлау_____________________________________________________________

(эшләрне башлау датасы)

8. Мәдәни мирас объектын саклау буенча мондый объектның конструктив һәм ышанычлылык һәм куркынычсызлык буенча башка сыйфатламаларына кагыла торган төзелешне, үзгәртеп коруны, эшләрне тәмамлау__________________________________________________________

(эшләрне төгәлләү датасы)

9. Тикшерүләр үткәрү программасына үзгәрешләр кертү нигезләре_________________________

_______________________________________________________________________________

(үзгәрешләр кертелгәндә тутырыла)

ТИКШЕРҮЛӘРНЕ ҮТКӘРҮ ПРОГРАММАСЫ

| № п/п | Төзелешне оештыру проекты нигезендә билгеләнә торган, тикшерүгә тиешле эшләрнең аталышы | Һәр тикшерүнең предметы | Һәр тикшерүне үткәрүнең якынча датасы | Тикшерү үткәрүгә дәүләт төзелеш күзәтчелеге органы вазифаи затының якынча сарыф ителәчәк вакыты | Тикшерүләрне үткәргәндә күрсәтелергә тиешле, тикшерүләр үткәрү программасында каралган документлар | Тикшерүләрне үткәрү программасында каралган тикшерүләрне үткәргәндә зарури катнашырга тиешле төзүченең, техник заказчының яисә төзүне башкаручы затның хезмәткәрләре һәм вазифаи затлар |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |
| | | | | | | |

__________________ ______________________ ______________________

(имзасы) (имзаның аңлатмасы) (вазифасы)

Килештерелде:

________________________________ __________ ____________________

(объект буенча дәүләт төзелеш күзәтчелеген башкару буенча җаваплы затны билгеләү турында боерык үтәлеше өчен җаваплы зат) (имза) (имзаның аңлатмасы)

Тикшерүләрне үткәрү программасының бер нөсхәсен алдым:
(төзүченең яки техник заказчының вәкиле тарафыннан, вәкиллек турындагы документ реквизитларын күрсәтеп тутырыла)

«___»_____________ 20__ ел.

__________________________ ______________ ______________________

(вазифа) (имза) (имзаның аңлатмасы)

Татарстан Республикасы
Дәүләт төзелешен күзәтү инспекциясе
тарафыннан Татарстан Республикасында
төбәк дәүләт төзелеш күзәтчелеге буенча
дәүләт вазифасын башкаруның
административ регламентына
6 кушымта

(Үрнәк рәвеше)

**Капиталь төзелеш объектын төзегәндә, үзгәртеп корганда тикшерелергә тиешле эшләрнең тәмамлану вакытлары турында**
**№______ хәбәрнамә**

______________________________________________________________________
(дәүләт төзелеш күзәтчелеге органы тарафыннан беркетелгән эш номеры)

_____________________________ «____»________________20_ ел.
(төзү урыны)

